Фаяз Хуҗин

# Кол Гали
# Кол Шәриф
# Сөембикә

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2009

УДК 821.512.145-3-93(093)
ББК 63.3(2Рос=Тат)6-8
Х80

**Хуҗин Ф.Ш.**

Х80 Кол Гали. Кол Шәриф. Сөембикә / Фаяз Хуҗин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 47 б.

ISBN 978-5-298-01771-8

Урта һәм өлкән яшьтәге мәктәп балаларына тәкъдим ителә торган бу китапта татар халкының өч бөек шәхесе – Кол Гали, Кол Шәриф һәм Сөембикә турында мәгълүмат бирелә. Ул студентларга, укытучыларга һәм, гомумән, татар тарихы, күренекле шәхесләребез белән кызыксынучы киң катлам укучыларга да кызыклы булыр.

УДК 821.512.145-3-93(093)
ББК 63.3(2Рос=Тат)6-8

ISBN 978-5-298-01771-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Хуҗин Ф.Ш., 2009

## Кадерле яшь дуслар!

Гомерем буе халкыбызның Борынгы һәм Урта гасырлар тарихы белән шөгыльләнеп, мин, ниһаять, бер нәрсәгә төшендем: тарихны – шанлысын да, фаҗигалесен дә – ахыр чиктә олы шәхесләр ясый икән. Элегрәк бу хакта ничектер уйлап җиткерә алмаганмындыр, күрәсең. Хәер, безне бит «халык – кешелек җәмгыятен алга әйдәүче, тарихны хәрәкәтләндерүче көч» дип өйрәтеп үстерделәр. Юк, һич тә, халык – көтү ул, көтүчесе кая куса, халык шул якка бара, дип әйтергә җыенмыйм. Ул да тарихның хәлиткеч мизгелләрендә үз сүзен әйтә белә. Һәм ничек кенә әле! Күпме ханнар-патшалар, гади халыкның ризасызлыгына, гаделсезлекләргә каршы кораллы чыгышлар басымына түзә алмыйча, тәхетләреннән ваз кичәргә мәҗбүр булганнар. Ничәмә-ничә тапкыр, яу кырларында явыз дошманнарны җиңеп, ватаннарын коллыкка төшү куркынычыннан саклап калганнар. Әйе, халык – көч ул! Ә шулай да... Уйлап карагыз әле: әгәр дә шул халыкны патшаларның җәберләүләренә, дошман яуларына каршы күтәрүче, җиңүләргә рухландыручы бер батыр, акыллы һәм зирәк шәхес булмаса, нәрсә булыр иде микән?

Халык һәм шәхес! Тарихыбызда һәркайсының үз урыны бар, минемчә. Явыз Иваннары, Кол Шәрифләре бар. Берәүләр халык хәтеренә җанкисәрләр, сатлыкҗаннар, икенчеләре исә гадел хөкемдарлар, үксезләр бәхете өчен аяусыз көрәштә танылган батыр йөрәкле көрәшчеләр сыйфатында урын алган. Андый шәхесләр булмаса, тарихыбыз күпкә ярлыланыр иде.

Татар тарихы олы шәхесләргә бай. Кызганыч, без аларның барысын да белеп бетермибез әле. Менә шуңа күрә дә Татарстан китап нәшрияты, үзенең яшь укучыларына атап, «Шәхесләр» дигән китаплар сериясе башлап җибәрергә уйлады. Бу бик изге ният! Кол Гали, Кол Шәриф һәм Сөембикә ханбикә кебек легендар шәхесләребез турында язарга кирәк дигән тәкъдимне мин ихлас күңелдән сөенеп кабул иттем. Алар – татарны татар итә, абруебызны дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрә торган шәхесләр. Безнең аларны онытырга хакыбыз юк!

Әйдәгез, шушы шәхесләребез яшәгән чорга сәяхәт кылып алыйк, иҗатларын, кылган гамәлләрен рәхмәт хисләре белән янә бер мәртәбә искә төшерик.

# КОЛ ГАЛИ

Калдырып тор юк-бар мәшәкатең,
Тыңлап кара чорлар тавышын.
Урап кайтыйк, әйдә, борынгыдан –
Заман белән заман кавышсын.

*Әхмәт Рәшит*

## Кол Гали – болгар шагыйре

Кайчак шулай да була икән: «Йосыф китабы» – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын гади халык шулай дип атап йөрткән – гасырлар буена укучылар кулыннан төшмәгән, күпләр аны яттан белгән, көйләп укыганнар, мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек рәвешендә кулланганнар, ә менә авторы турында уйлап та карамаганнар. Кем язган аны, кайсы төбәктә туган әсәр ул? Гади татар укучысы баш ватып тормаган: «Йосыф китабы» – безнеке, бетте-китте!» – дигән.

Галимнәр исә – кызыксынучан халык. Поэманың беренче кульъязма нөсхәләре кулга төшүгә үк, алар аның авторын ачыкларга тотыналар, кайчан һәм кайсы төбәктә язылган булуы турында фикерләрен әйтәләр. Гыйльми бәхәсләр башланып китә һәм ул бәхәсләрнең кайберләре бүгенге көннәргә кадәр дәвам итә.



Дөнья фәнендә «Кыйссаи Йосыф» поэмасына иң әүвәл Генрих Фляйшер исемле немец галиме игътибар итә. Ул бу әсәрне үзенең 1831 елда басылып чыккан китабында телгә ала. Баксаң, «Кыйссаи Йосыф» кульъязмасы Германиянең Дрезден шәһәрендәге мирасханәләрнең берсендә саклана икән. Г.Фляйшер шул кульъязманы табып ала. Ул XVII гасыр ахырында (XVIII гасыр башы булырга да мөмкин) Казанның Иске бистәсендә яшәүче тылмач Динмөхәммәд

Саттаров исемле бер татар тарафыннан язып алынган була. Кем белә, бәлки, бу кулъязма Дрезденга ниндидер юллар белән аның шәхси китапханәсеннән, үз китаплары арасыннан килеп эләккәндер?

Кызыклы факт, әлбәттә. Әмма татар зыялылары үзләре «Кыйссаи Йосыф»ка бөтенләй игътибарсыз булганнар икән дип әйтергә ашыкмыйк. XVIII йөздә иҗат итә башлаган атаклы татар галиме һәм шагыйрь Габдерәхим Утыз-Имәни әл-Болгари (1754–1834) «Кыйссаи Йосыф»ның күп кенә борынгы кулъязмаларын җыя, аларны чагыштырып өйрәнә һәм әсәрнең төп текстын басмага әзерли. Китап 1839 елда Казан университеты нәшриятында дөнья күрә. Шуннан башлап ул һәр елны диярлек зур тиражлар белән чыгып тора һәм Көнчыгышны өйрәнүче галимнәрнең югары бәясенә лаек була. Поэманы фәнни нигездә ныклап өйрәнү башлана. Телен, шигъри үзенчәлекләрен, сәнгатьчә эшләнешен җентекләп тикшерәләр. Иң әүвәл авторының кайсы халык вәкиле булуын ачыкларга тырышалар. Шунда бәхәсләр, фаразлар башлана да инде.

Бәхәсләшер өчен нигез була, әлбәттә. Без алар турында соңрак сөйләрбез әле. Хәзер исә «Кыйссаи Йосыф»ның авторы белән танышыйк. Баштан ук кисәтергә кирәк дип табам: белешмәләребез бик аз, булганнары да поэмада китерелгән кыска гына фактлардан һәм халык телендә сакланып калган кайбер риваятьләрдән гыйбарәт.

Поэманың тәмамлау өлешендә шагыйрь үзе турында болай ди:

Моны язган зәгыйфьнең аты – Гали,
Егерме дүрт иҗек белән төзде юлны...

Өмет баглыйм мин гөнаһлы Син таңрегә,
Шәфкатьле һәм мәрхәмәтле Син иямә,
Кыл мәрхәмәт-шәфкать миңа – Кол Галигә,
Кайгылы бу җанымны син шат кыл имди.

Тагын бер мәгълүмат: шагыйрь әсәренең язылып бетү вакытын күрсәтә:

Мәүлям миңа кылган ярдәм аркасында,
Изге, бөек рәҗәп ае утызында,
Тарих елының алты йөз тугызында
Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде имди.

Димәк, «Кыйссаи Йосыф»ка һиҗри белән 609 елда, рәҗәп аеның 30 нчы көнендә нокта куелган. Хәзерге календарьга күчереп исәпләсәң, бу 1212 елның 9 декабре була. Ләкин поэманың безнең көннәргә кадәр сакланган кайбер нөсхәләрендә аның тәмамлану датасы итеп һиҗри белән 630 ел, рәҗәп аеның 30 нчы көне күрсәтелгән. Бу безнеңчә 1233 елның 13 апреленә туры килә. Кайсысы дөрес? Галимнәр соңгы датаны хуплыйлар, төрле дәлилләр китереп, «Кыйссаи Йосыф»ны 1236 елгы монгол-татар яулары алдыннан язылган дип карыйлар. Без дә шул фикергә кушылабыз.

Легенда-риваять ише халык авыз иҗаты әсәрләре тарихи чыганаклар, ышанычлы документлар була алмый. Әмма аларны читләтеп үтү дә ярамас кебек. Миңа калса, аларда хакыйкатькә якын торган вакыйгалар чагылыш тапкан.

1806 елда Таҗетдин Ялчыгол «Тәварихы Болгария» («Болгар тарихы») дигән хезмәтен яза. Биредә китерелгән бер легендада Кол Галинең нәсел-нәсәбенә караган юллар да бар. Имеш, Болгарга яу белән килгән Аксак Тимер Габдулла ханны үтертә. Соңыннан Габдулланың Галимбәк исемле бер улы Кашан шәһәрендә нигезләнә, анда имам вә мөдәррис була. Галимбәкнең Мирхаҗи исемле улы була. Кол Гали – Болгар иленең асыл шаһзадәләреннән саналган Мирхаҗи бәкнең углы, имеш. Утыз ел чамасы шәһри Кашанда гомер кичереп, Мирхаҗи Зәй якларына күчеп килә, Бараҗ ханда имам булып тора. Кол Гали шул төбәктә туа, зирәк, акыллы егет булып үсә. Белем эстәп, Харәзем якларына чыгып китә, биредә укый һәм 45 ел буена мөдәррислек итә. Аннан соң, Кытай якларыннан килгән Туси исемле бер патша Харәзем җирләрен яулап алгач, атасы йортына – Зәй тамагына кайта. Ул 110 яшендә, Аксак Тимернең Биләргә һөҗүме вакытында шәһит була, имеш.

Бәхәсләшерлек урын юк: Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихы Болгария»се – төрле уйдырмалар, очы очка ялганмаган әкияти, чынбарлыктан ерак торучы вакыйгалар белән тулган үзенчәлекле бер әсәр. Әмма бу вакыйгаларны бит Ялчыгол үзе уйлап чыгармаган. Әлеге тарихи «фактларны» ул борынгы кулъязмалардан, шәҗәрәләрдән алган. Алар арасында күчермәләре XVI йөзгә карый торганнары да бар. Димәк, Кол Галинең тәрҗемәи хәленә кагылышлы кайбер вакыйгаларның тарихи дөреслеккә туры килүе бик мөмкин. Мәсәлән, Т.Ялчыгол шагыйрьнең үлемен Аксак Тимер яулары белән бәйли. Бу җиһангир (яулап алучы) Болгар иленә 1390 елларда һөҗүм итә. Әлбәттә, үзенең әсәрен 1233 елда язып тәгәлләгән шагыйрь 1399 елга кадәр яшәмәгән. Әмма татар риваятьләрендә Аксак Тимер яуларын еш кына Батый хан яулары белән бутап бирәләр. Бөек Биләр каласын да, риваятьләргә ышансаң, Аксак Тимер җимереп ташлый, имеш. Чынбарлыкта исә Биләрне 1236 елда Батый хан гаскәрләре тар-мар итә. Туси ханның чын исеме Җүчи булган дип уйларга нигез бар. Монголлар Харәземне чыннан да 1219–1221 елларда яулап алалар. Бу – язма чыганаклар белән дә, археология материаллары белән дә төгәл исбатланган факт. Миңа калса, Кол Гали нәкъ менә 1236 елның көзендә Биләр өчен барган аяусыз сугышларда һәлак булган, Аксак Тимер яуларында түгел.

Ә нишләп әле шагыйрьнең Урта Азия шәһәрләрендә, гыйлем үзәкләрендә олы галимнәрдән дәресләр алып укыганлыгын инкарь итәргә ди? Заманы өчен табигый күренеш ул. Дөрестән дә шулай булган.

Кашан һәм Зәй тамагы белән бәйле сюжетларны аңлату бераз катлаулырак, әмма алары да кеше ышанмаслык түгел. Кол Галинең кайбер риваятьләрдә китерелгән туган елы – 1183 ел. Аны Болгар иленең ул чордагы башкаласы Биләрдә туган диючеләр дә бар. Шулай икән, «Кыйссаи Йосыф»ны шагыйрь 50 яшендә иҗат иткән булып чыга. Өч елдан соң, ягъни 53 яшендә мәңгелеккә күчә. Күргәнебезчә, Ялчыгол китабында бәян ителгән һәм ул китапка кермәгән башка риваятьләрдән кул селтәп баш тартырга ярамый. Киресенчә, булган барлык чыганаклар белән чагыштырып, тагын да җентекләбрәк өйрәнергә кирәк аларны.



Биләрне төзекләндерү.
Рәссам *Фиринат Халиков*
картинасыннан репродукция

Безнең алда тагын бер сорау: Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы кайда язылган, ягъни кайсы халыкка нисбәтле? Гади генә итеп әйткәндә, Кол Гали кайсы милләттән? Бу сорауга тиз генә җавап табып булмый, чөнки Кол Гали поэмада үзенең милләтен күрсәтмәгән, мин – болгар дип язып калдырмаган. Кол Гали исеме башка төрки халыкларда булмаган дип әйтә алмыйбыз. Югарыда китерелгән риваятьләргә таянып, без аның болгар кавеменнән булу мөмкинлеген фаразлыйбыз гына. Ә бу фаразны тагын да төплерәк дәлилләр белән ныгытырга кирәк. Бу очракта игътибарыбызны поэманың тел үзенчәлекләренә юнәлтергә тиешбез.

Мәгълүм ки, шагыйрьләр гади халык теленнән шактый ерак торган әдәби телдә иҗат итәләр. Кол Гали кулланган әдәби телнең үзенчәлекләре бар. Поэмадан бер мисал:

Гәүһәр даш вә ләйкин даш улмаз,
Дикмә кеши гәүһәр кадрен кийас кыйлмаз.
Бу нәземнең кадрени ахмак белмәз, –
Гакыйл кеши дыңлар, аңлар, беләр имди.

Хәзерге әдәби телгә күчермәсе:

Гәүһәр – таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,
Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас.
Бу нәзымның кадрен һич ахмак белмәс, –
Гакыллылыр тыңлар, аңлар, белер имди.

Телче галимнәр фикеренчә, Кол Гали поэмасының теле огуз, ягъни хәзерге төрекмән, төрек теле элементларына бай: *д*аш (*т*аш), *д*ыңлар (*т*ыңлар), *д*икмә (*т*икмә) кебек сүзләр, *-мыш* / *-меш* кушымчалары һ.б. Уйгур-карлук һәм кыпчак (борынгы татар) телләренең үзенчәлекләре дә Кол Гали өчен чит түгел. Шулай булырга тиеш тә, чөнки поэма Урта гасырлар шигърияте дөньясында, шул исәптән



Билэрдәге Җәмигъ мәчете макеты. X – XIII гасыр башы. Реконструкция авторы – архитектор *Нияз Халит*

Урта Идел төбәгендә дә киң таралган катнаш төрки телдә язылган. XVIII – XIX йөзләрдә иҗат иткән чын татар шагыйрьләренең телләрен дә аңлау авыр. Хәтта Тукай шигырьләрендә дә гарәп-фарсы алынмалары күп. Аны бит гарәп йә булмаса фарсы шагыйре димиләр. Ә менә кайбер галимнәр «Кыйссаи Йосыф»ның авторын хәзерге Төркия җирлегеннән, Урта Азия якларыннан эзлиләр. Аларның ялгышын татар галимнәре ачыклады инде. Төп һәм иң ышандыргыч дәлилләре шул: «Кыйссаи Йосыф»ның безгә мәгълүм барлык кулъязмалары да татарлар яши торган төбәкләрдә табып алынган диярлек. Башка төбәкләрдә яшәүче төрки халыклар поэманы белмиләр, димәк, үзләренеке итеп санамыйлар.

Тагын бер нәрсә бар. Кол Гали иҗат иткән чорга әйләнеп кайтыйк әле. Ул Болгар илендә – Идел Болгарстанында туган, яшәгән һәм иҗат иткән. Чит илләрдән килеп йөргән сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр Болгар илен «бай шәһәрләре белән данлыклы, көчле һәм бөек дәүләт» дип атаганнар. Бу сүзләрдә бернинди арттыру да юк. Хәзерге заман галимнәре дә Болгар илен «шәһәрләр цивилизациясе» диләр. Археологларга мәгълүм 170 ләп болгар каласының өч дистәдән артыгы үзләренең зурлыклары, димәк, халык саны буенча да Русь, хәтта Европа шәһәрләрен узып киткәннәр. Алар арасында илнең ул вакытлардагы башкаласы Биләр иң атаклыларыннан саналган. Шәһәр үзәгендә 922 елда, Алмыш ханга Багдад илчелеге килгән вакытта салынган Җәмигъ мәчете балкып торган. Аның янында гына җәмәгать мунчасы урнашкан. Олы базарда сәүдәгәрләр үз товарлары белән сату иткәннәр. Кирпечтән-таштан салынган йортларның исәбе-хисабы булмаган.

Биләр, Суар, Кашан һәм эреле-ваклы башка шәһәрләрдә һөнәрчелек чәчәк аткан. Тимерчеләр һәм бакырчылар, зәркәнчеләр һәм күнчеләр, пыяла ясаучылар һәм башка һөнәр ияләре җитештергән югары сыйфатлы товарлар дөнья базарында дан тоткан.

Идел болгарлары мәдәниятле халык булган. Нәфис итеп сөяктән ясалган язу каләмнәре, кара савытлары, асылташлар белән бизәлгән китап тышлыклары, язулы йозаклар, шахмат фигуралары – борынгы болгар мәдәниятенең археологиядә чагылыш тапкан бер өлеше генә. Гарәп язучысы Ибн Рөстә хезмәтләреннән исә болгар бабаларыбызның әле X гасыр башларында ук мәчет-мәдрәсәләре, мәктәпләре булганлыгын беләбез. Бу мәктәпләрдә ислам нигезләрен өйрәнгәннәр, тарих, география, арифметика, астрономия һәм башка фәннәр буенча башлангыч белем алганнар. Сәләтле яшьләрне Шәрык илләренә җибәреп укытканнар. Шул яшьләр арасыннан үсеп чыккан Әбү Хәмид бине

Шагыйрь Кол Гали.
Рәссам *Канәфи Нәфыйков* картинасыннан репродукция



Идрис әл-Болгари, Борhанеддин бине Йосыф әл-Болгари, Сөләйман бине Дауд әс-Саксини әс-Суари, Таҗеддин бине Хөсәен әл-Болгари кебек атаклы галимнәр төрле фәннәр буенча күләмле хезмәтләр язып калдырганнар. Бу хезмәтләрнең бер өлеше әле дә Тәһран һәм Истанбул мирасханәләрендә саклана.

Без моның белән, Идел Болгарстанында Кол Галинең шагыйрь буларак формалашуына барлык уңай шартлар да булган, дип әйтмәкче булабыз. Ә менә Урта Азия якларында 1233 елда ул үз әсәрен яза алмас иде. Чөнки биредәге дәүләтләрнең барысы да монгол-татар яулары вакытында басып алынган, шәһәр-калалар җимерелгән булган.

Шикләнүләрсез әйтергә мөмкин: Кол Гали үзенең мәшһүр әсәрен Болгар илендә, Биләр каласында, монгол яулары алдыннан язып төгәлләгән һәм аның, поэманың, бөтен төрки дөньяга таралуына да шул яулар-сугышлар, тынычсыз вазгыять комачаулаган.

## «Кыйссаи Йосыф» поэмасы

Хәзер инде, дуслар, игътибарыбызны әсәрнең эчтәлегенә юнәлтик.

Ягкуб пәйгамбәрнең унике баласы арасыннан иң сөеклесе, башкалардан илаһи чибәрлеге белән аерылып торганы, әле унбер яшен яңа гына тутырган Йосыф исемлесе беркөн хикмәтле төш күрә. Имештер, кояш, ай һәм йолдызлар аның каршына төшеп баш игәннәр. Уянгач, аңлатып-юрап бирүен үтенеп, Йосыф төшен атасына сөйли:

Нурлы кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз
Шул төшемдә сәҗдә кылды миңа төп-төз,
Бу төшемне шулай күрдем, һичбер шиксез, –
Йә, әткәем, шул төшемне юра имди.

Атасы төшне бик зур дәрәҗәгә ирешү галәмәте дип фаразлый, аны беркемгә дә сөйләмәскә, сер итеп сакларга куша. Әмма Ягкубның үги кызы әлеге сөйләшүне ишетеп кала һәм аны шунда ук агаларына җиткерә. Тегеләрнең күңелләрендә көнчелек хисе кабына һәм алар Йосыфтан үч алырга карар кылалар. Әтиләреннән Йосыфны үзләре белән сахрага алып чыгарга рөхсәт сорыйлар. Ягкуб

ризалыгын бирми, аның күңеле нидәндер шикләнә. Йосыфның исә сахрага чыгып уйныйсы килә. Ул атасының муенына сарылып ялвара, абыйлары белән җибәрүен үтенә. Ягкубның күңеле түзми – ризалыгын бирә.

Менә ул иртәгесен сөекле баласын агалары кулына тапшыра. Тегеләр, аталары алдында кадерхөрмәт күрсәткән булып, Йосыфны иңнәренә күтәреп китәләр. Йорттан ераклашуга, аталары күздән югалу белән, Йосыфны төрлечә кыерсыта башлыйлар. Хәтта үтермәкче булалар. Ахыр чиктә Йосыфны, аягын-кулын бәйләп, ташландык коега ыргыталар. Кич белән өйгә кайткач, әтиләренең: «Кайда минем Йосыфым?» – дигән соравына, алдалап: «Йосыфны бүре ашады, менә билгесе», – дип, энеләренең кәҗә бәтие канына буялган күлмәген күрсәтәләр. Ата кеше һуштан язып егыла...

Еллар үтә. Олы кайгыдан, моң-зар чигүдән Ягкубның күзләре сукырая.

Алдагы вакыйгалар болайрак дәвам итә.

Аллаһы Тәгалә боларның барысын да күреп-белеп тора. Әлбәттә, бер гөнаһы булмаган сабыйга ул ярдәмгә килә: Йосыфны коега ташлау белән, кое төбендәге таш су өстенә калкып чыга һәм «ефәктәй йомшакка әйләнә». Йосыф шунда барып төшә. Өч көн вакыт үтә. Менә берзаман кое янына сәүдә кәрваны килеп туктый. «Чиләкләрен шулай суга батырганда, чиләк тутырып мөлдерәмә су алганда», ни күрсеннәр, бауга ябышып, коедан бер малай чыга. Кәрванчылар аның – Йосыфның – гүзәллеген күреп чак кына һушларыннан язмыйлар. Алар аны, читкәрәк алып китеп, бер урынга яшереп куялар.

Кәрванчылар янына Йосыфның шул тирәдә генә көтү көтеп яткан туганнары килеп җитә. Коены карыйлар – Йосыф юк. Эшнең нидә икәнлеген тиз аңлап алалар. «Бер колыбыз бездән качып киткән иде, аны сез алгансыз», – дип, кәрван башлыгына ташланалар.

Кәрванчылар юк кына бәһагә Йосыфны сатып алалар. «Сатмагыз!» – дип елап-елап ялварса да, баланы тыңлаучы булмый. Туганнар кала, кәрван үз юлы белән китеп бара. Куллары богауланган Йосыфны сакларга «иң гайрәтле, кара йөзле, үзе усал, каты куллы» Кылыч исемле бер колны куялар.

Юл Йосыфның газиз әнкәсе күмелгән зират яныннан үтә. Нарасый бала Кылычтан рөхсәт сорап тормыйча дөя өстеннән төшә һәм әнисенең кабере янына китеп бара.

Берзаман теге сакчы карый – Йосыф юк. Нишләргә? Якын-тирәдән эзләп таба алмагач, хәлне кәрван хуҗасына белдерә. Кәрван туктап кала, барысы да җыйнаулашып Йосыфны эзлиләр. Бераздан Кылыч Йосыфның кабер өстендә елап ятканын күрә. Йөгереп килеп, мескен Йосыфны кыйнап ташлый, йөзенә камчы белән суга, җирдән сөйрәп йөри.

Шул мәлдә күкне кара болыт каплап ала, көчле җил куба, карлы-бозлы яңгыр ява башлый. Куркып калган кәрван хуҗасы юлдашларына әйтә:

...Күк ачуы бу, белегез,
Җәбер-золым кылучылар, сафланыгыз,
Һәм итегез тәүбә, булса гөнаһыгыз, –
Юкса һәммәбез дә һәлак булыр имди.



Кәрван. Рәссам *Равил Заһидуллин* картинасыннан репродукция

Кылыч үзенең Йосыфны ничек итеп мәсхәрәләвен, кылган рәхимсезлекләрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Барысы да, Йосыф каршысында тезләнеп, кичерү сорыйлар. Шул ук мизгелдә карлы-бозлы яңгыр тына, кояш чыгып, җир йөзе шатлангандай була. Кәрван хуҗасы юлдашларына фәрман бирә:

Һәммәгез дә Йосыфка сез буйсынасыз,
Олы-кече, һәммәгез хезмәт кыласыз.
Моннан ары башлык дип беләсез, –
Аның әмереннән чыкмагыз һичбер имди.

Йосыфка иске кием урынына күлмәк кидерәләр, дөядән төшереп, атка утырталар. Кәрван үз юлын дәвам итә. Артта бер-бер артлы шәһәрләр кала. Барча халык, Йосыфка сокланып, кәрванчыларга кадер-хөрмәт күрсәтә:

«Әйт, – диделәр, – сине болай кем бар итте,
Йөзең болай күркәм итеп кем яратты,
Бизәкләрен салды кем бу чаклы? –
Булыр идек без дә аның колы имди».

Йосыф әйтте: «Алла мине бар кылучы,
Җирдә, күктә без колларын туйдыручы,
Бу көчләргә лаек бары Аның көче, –
Сезне, безне Ул яратты, белегез имди!»

Бу сүзләргә һәммәсе дә инандылар,
Бер Аллага һәммәсе дә табындылар,
Йосыфның пәйгамбәрлеген таныдылар, –
Чын күңелдән мөэмин булды алар имди.

Ниһаять, сәүдә кәрваны Мисыр иленә килеп җитә. Мисыр халкы, Йосыфны күреп, хәйран кала. «Ул, – диделәр, – адәмнәргә охшамаган, күктән иңгән фәрештәдер». Шәһәр халкы Йосыфны күрергә ашкына. Кәрван башлыгы бу хәлдән файдаланып калырга була, Йосыфны зиннәтле сарайның уртасына куелган урындыкка утыртып, бер динар акча бәясенә халыкка күрсәтә. Икенче көнне бәяне ике динар итеп билгели, шулай ун көн буена бәяне берәр динарга арттыра барып, Йосыфтан файда күрә. Аннан соң «гүзәл товарын» базарга чыгара, Йосыфны кыйммәт бәягә сатарга теләге барлыгын ишеттерә. Алырга теләүчеләр арасында «олы-кече, бай һәм фәкыйрь, хәлвәчеләр, икмәкчеләр» – бик күпләр була. Әмма затлы колны сатып алырга берсенең дә хәленнән килми.

...Беркөнне базарга Мисыр хөкемдары Кыйтфир һәм аның хатыны Зөләйха килә. Беренче тапкыр без Зөләйха белән шунда очрашабыз. Зөләйханың тарихы әсәрдә болайрак сурәтләнә. Ул Мәгърибтә патша булып торучы Тәймуснең кызы була. Бервакыт ул төшендә Йосыф сурәтен күрә. Уянгач та төшендә күргән гүзәл сурәт тәэсиреннән айный алмый, ашамас һәм эчмәс була, йокыдан кала. Ата-анасы чарасызлыктан аптырый. Үзен сорап төрле яктан никадәр баһадир шаһзадәләр, ханзадәләр килсә дә, берсенә дә әйләнеп карамый. Бер елдан Зөләйха янәдән шул ук сурәтне күрә. Сурәт, телгә килеп, кызга дәшә:

Син бел шуны: син – минеке, мин – синеке,
Була күрмә миннән башка һичкемнеке,
Онытма бу гыйшкым нинди иконлекне, –
Миннән үзгә һичкемгә күз салма имди!

Кыз уянып китә, хыялын яулаган затның юкка чыгуыннан һушын югалта, хәсрәтләнә, өзгәләнеп елый.

Мәхәббәт газабында тагын бер ел вакыт узып китә. Кыз сурәтне янә төшендә күрә. Зөләйха егеттән сорый: «Әйтче, кем син, торган җирең кайда?» – ди. Йосыф телгә килә, үзенең Мисыр хөкемдары булуын әйтә, мине күрергә теләсәң, Мисырга кил, шунда табарсың, ди. Бу эшне сабырлык белән, ашыкмыйча эшләргә киңәш итә. Зөләйха төшен атасына сөйли, гозерләнеп, үзен Мисырга озатуын үтенә. Тәймус патша Мисыр хөкемдары Кыйтфиргә хат яза: «Бер кызым бар, ул тик сине теләр имди, риза булсаң, безгә белдер, үз илчеңне җибәр имди». Тиздән Мисырдан уңай хәбәр килә һәм Тәймус, кәрванга затлы бирнәләр төяп, кызын ерак юлга озата.

Татлы хыяллар белән Зөләйха Мисыр иленә килеп җитә, хәзер теләгемә ирешәм дип, Йосыф белән очрашуга әзерләнә. Әмма вакыйгалар катлауланганнан-катлаулана гына бара. Кыз хозурына хыялындагы гүзәл егет урынына олы яшьтәге Кыйтфирне китерәләр. Зөләйха һуштан язар чиккә җитә:

Мондый түгел иде минем төшкә кергән,
Лаек түгел бу ир миңа, ачык күрәм,
Охшашы юк моның һич тә аның белән, –
Гакылы, күрке аның мондый түгел имди.

Тулган айдай балкыр иде аның йөзе,
Бал-шикәрдән татлы иде аның сүзе,
Рәхәт таба иде хәсрәт чиккән кеше, –
Ансыз миңа бөтен дөнья ямьсез имди.

Сарай хезмәтчеләре кызны юаталар, сабыр бул син, сабырлык белән генә морадыңа ирешә алырсың, диләр. Зөләйха Мисырда, патша сараенда торып калырга мәҗбүр була. Язмышына буйсына, әмма үзенең пакьлеген саклый. Кыйтфир янына, Зөләйха кыяфәтенә кереп, пәри кызы йөри.

Күп вакытлар үтә. Йосыфның язмышы да, инде күргәнегезчә, Мисыр белән бәйләнә.

Менә беркөн Йосыфны мәйданга алып чыгалар. Зөләйха да шунда була. Базар мәйданында: «Бу угланны сатып алыр кем?» – дигән игълан яңгырый.

Зөләйха, уйлап та тормыйча, хезмәтчеләренә: «Минем өчен аны сатып алыгыз, барлык малымны шуңа фида кылыгыз, нинди бәһа сорасалар да бирегез!» – дип боера. Кыйтфир патша сәүдәгәрдән колның чын бәһасен белә һәм, бөтен шартларын үтәп, аның үлчәвенә Йосыф авырлыгындагы алтын-көмеш куя. Ахыр чиктә Мисыр патшасының хәзинәсендә берни дә калмый. Йосыф аркасында мохтаҗлыкка төштек, дип уфтана башлый ул. Йосыф аңа казнасын тикшереп карарга тәкъдим итә. Ә казнадагы хәзинә үз урынында, мал-мөлкәт кимемәгән. «Бу бары тик Аллаһ кодрәте белән шулай булды, – дип аңлата Йосыф эшнең асылын. – Белеп торыгыз: хәзер мин сезгә һич бурычлы түгел». Шуннан соң Кыйтфир патша Йосыфны Зөләйха кулына илтеп тапшыра.

Алты-җиде елдан Йосыф буй җиткән егеткә әверелә. Зөләйханың аңа карата гыйшык уты тагын да көчлерәк булып яна башлый.

Бер җай чыгып, Зөләйха хәлләрен тәрбияче хатынга сөйли. Тегесе зиннәтле сарай салырга киңәш итә. «Йосыфны шул сарайга чакырырсың, гүзәллек эчендә иң гүзәле син икәнне күргәч, ул акылын югалтачак, сиңа буйсыначак», – ди.

Тиздән сарай әзер була.

Менә Йосыф Зөләйха хозурында. Кыз егеткә булган гыйшкын ачып сала. Йосыф исә, Зөләйхага ихтирам саклаган хәлдә, аның мәхәббәтен кире кага. Атасы урынына калган Кыйтфир патшага хыянәт итү турында уйлап та карамый.

Әлеге вакыйга икенче көнне үк бөтен Мисыр халкына мәгълүм була. Имеш, Зөләйха үзенең колына гашыйк булган. Тегесе, имеш, аңа буйсынмаган... Китә гайбәт, төрле сүзләр, усал көлешүләр.

Зөләйха мондыйларга сабак бирергә була. Зур мәҗлес әзерләп, табынга аксөякләрнең хатыннарын чакыра. Һәрберсенә пычак һәм әфлисун бирә. «Әфлисунны турагыз!» – дип боера. Нәкъ шул вакыт залга Йосыф килеп керә. Хатын-кызлар егетнең гүзәллеген күреп таң кала.

Шулай алар сихерләнеп карадылар,
Үзләренең бармакларын турадылар,
Турауларын һич кенә дә тоймадылар, –
Һәммәсе дә шулкадәрле хәйран имди.

Зөләйха әйтте: «Инде сез күрдегезме,
Йөзем нидән сулганлыгын белдегезме,
Бер күрүдә кулыгызны кистегезме, –
Акылыгызны җуйдыгызмы?» – дияр имди.

Нәкъ җиде ел инде аны мин күргәнгә,
Гыйшкым аңар көчәядер көннән көнгә,
Гаҗиз булдым, чара тапмыйм мондый хәлгә, –
Димәк, сабырым сезнекеннән артык имди.

Зөләйха катгый карарга килә: «Асыл егет әмремә йә буйсына, йә яптырам – зинданда ул тоткын була». Йосыф унике ел буена зинданда ятарга мәҗбүр ителә.

Шулай бервакыт икмәкче белән шәрабчыны, патшаны агуларга җыенуда гаепләп, Йосыф янына зинданга ябалар. Икесе дә төш күрә. Йосыф боларның төшләрен юрый: шәрабчының котылып, кире үз вазифасына кайтачагын, икмәкченең исә җәзаланачагын әйтә. Шулай булып чыга да. Зинданнан котылып чыгар алдыннан Йосыф шәрабчыга үзенең гозерен җиткерә: «Әйт патшага белгәнеңне, аңлатып бир минем бер гөнаһсыз икәнемне», – ди. Теге вәгъдә бирә, әмма тоткынлыктан котылуга үз вәгъдәсен оныта.

Шулай беркөн зиндан янына гарәп сәүдәгәре килеп туктый. Ул Йосыфның туган якларыннан була. Йосыф, атасының хәлләрен сорашып, углын югалтудан күргән кайгы-хәсрәттән атасының күзләре сукыраюы хакында ишетә. Күңеленнән елый, сәламнәр күндерүен үтенә, тик үзенең исемен әйтми. Туган иленә кайткач, әлеге гарәп Ягкуб карт белән очраша, аңа Мисырда булган хәлләрне сөйләп бирә, зинданда җәфаланып ятучы тоткынның сәламен тапшыра. Бу хәбәр ата күңелендә ниндидер өмет уята.

Менә беркөн Мисыр патшасы гаҗәп төш күрә: имеш, җиде симез сыерны җиде арык сыер тотып ашый, тулып җиткән җиде башакны корып беткән җиде буш башак йота. Сарайдагылар төшне юрый алмый. Йосыф белән кайчандыр бер зинданда утырган шәрабчының исенә кылт итеп шул тоткын килеп төшә – хикмәтле төшнең мәгънәсен ул гына аңлатып бирә алыр. Патша шәрабчыны зинданга чаптыра. Йосыфның юравы болай була:

...Нәкъ җиде ел иген уңа,
Төрле нигъмәт-азык белән дөнья тула,
Аннан соңра корылык һәм кытлык була, –
Нәкъ җиде ел зур авырлык булыр имди.

Бу хәвефле хәбәрне ишеткәч, патша шундук Йосыфны тоткынлыктан азат итә. Аны каршыларга бөтен Мисыр халкы чыга, юлына алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән сибәләр.

Патша белән сөйләшкәндә, Йосыф аңа алдан ук илне киләсе ачлыктан саклау чараларын күреп куярга киңәш итә. Йосыфның акылына, белеменә таң калган хөкемдар патшалыкны ике дә уйлап тормастан аңа тапшыра. Йосыф ачлык чорына әзерләнә башлый: күп иген иктерә, амбарлар төзетә, еллык уңышның биштән берен дәүләт амбарларына салдыра, сугылмаган ашлыкны башакта килеш калдырырга боера...



*Бакый Урманче* эшләгән шәмаил. Бронза, тушь, кәгазь.

Анда Кол Галинең:
«Гәүһәр ташдыр, ләкин һәр таш гәүһәр улмас,
Гәүһәр кадерен тикмә кемсә кыяс кыйлмас», – дигән сүзләре язылган.

Хәзер инде яңадан Зөләйхага әйләнеп кайтыйк.

Йосыф, йөгерек атына атланып, күпсанлы гаскәре белән сахрага чыга. Көтмәгәндә бер тавыш ишетеп, туктап кала. Караса, бер читтәрәк күзләре сукырайган, иске-москы киемнәр кигән бер зәгыйфь карчык басып тора. Йосыф атын туктата, мескен карчыкка якынрак килә һәм сорый: «Кем буласың, миңа нинди йомышың төште?» – ди. Бу карчык... Зөләйха булып чыга. «Кырык ел буе синең гыйшкыңда янып, шундый көнгә калдым», – дип аңлата ул үзенең хәлен. Тетрәндергеч язмыш! Моңа Йосыфның ышанасы да килми хәтта.

Йосыф шул чак Зөләйханы бик кызганды,
Аның мондый гыйшкына ул таңга калды,
Зөләйханың сүзләренә ышанмады, –
Сынау өчен кабат сорау бирер имди.

Йосыф әйтте: «Әгәр чынлап гашыйк булсаң,
Гыйшыклыкта чын тугрылык саклый алсаң,
Гыйшык зарын аңлауга дәгъва кылсаң, –
Бу дәгъвага бирәр дәлил кирәк имди».

Зөләйха озак уйлап тормый, чын мәхәббәтен аңлатуның үтемле юлын таба – Йосыфтан кулындагы камчысын сорый. «Гашыйк булсам, камчы сиңа моны үзе күрсәтер», – ди.

Йосыф, килеп, аңа үз камчысын сонды,
Хатын камчыга өрде дә кире бирде,
Камчыга ут кабынганын Йосыф күрде, –
Камчы, янып, Йосыф кулын пешерер имди.

Тугры Йосыф ул камчыны атып бәрде,
Зөләйханың гашыйклыгын ачык белде,
Һич калмады шиге, тугрылыгын күрде, –
Гаҗәпләнеп, ат тезгенен тартыр имди.

Зөләйха әйтте: «Күрдеңме, аңладыңмы,
Камчыга ут кабуга таң калдыңмы?
Кулыңны пешергәнгә түзалмадыңмы? –
Ул ут мине кырык ел көйдерә имди!»

Шул рәвешчә Йосыф Зөләйханың хаклыгын, хисләренең ихласлыгын, сүзләренең тугрылыгын

аңлый. Аллаһы Тәгалә һәм пәйгамбәрләр ярдәме белән Зөләйхага яшьлеге кире кайта: күзе ачыла, тулган айдай йөзе нурдан балкый.

Аннан соңра Хак тәкъдире шулай булды,
Алар икәү гомер буе бергә торды,
Хода аларга унике ул бүләк кылды, –
Олысына Мөсалим диярләр имди.

...Кайчандыр Йосыф үзе юраган корылык килеп җитә. Мисыр һәм күрше илләр халкы ачлыктан интегә. Ягкуб үз янына улларын чакырып ала: «Ашлык сорап, Мисыр патшасына барырга кирәк, аның бик игелекле һәм юмарт дигән даны дөньяга таралган, башка чарабыз юк», – дип белдерә. Ун туган (унберенчесен, Йосыф белән бер анадан туган Ибне-Йәминне, Ягкуб үз яныннан җибәрми) сәфәр чыгалар.

Йосыфка кардәшләренең Мисырга килеп җитүен ишеттерәләр. Ул аларга зур хөрмәт күрсәтә: сараена чакыра һәм төрле нигъмәт-ризыклар белән сыйлый. Икенче юлы очрашканда, аталарының хәлен сораштыра. Шулай сый-хөрмәт күрсәтеп, йөкләренә күп итеп ашлык төяп, агаларын өйләренә озата. Юлга кузгалыр алдыннан Йосыф туганнары арасыннан берсен үз янында калдыруларын сорый. Һәм болай дип өсти:

Сезнең яктан чын тугрылык булыр исә,
Ибне-Йәмин сезнең белән бергә килсә,
Җибәрергә атагыз һәм риза булса, –
Бер түләүсез бик күп ашлык бирәм имди.

Кайткач, Йосыфның туганнары Мисырда булган хәлләрне түкми-чәчми аталарына сөйлиләр. Бу хәлләрне ишетеп, Ягкуб карт бик шатлана.

Менә алар, Ибне-Йәминне дә ияртеп, янәдән Мисыр патшасына юнәләләр. Аталарының кушуы буенча, шәһәр капкасыннан икешәр-икешәр булып керәләр. Ибне-Йәмин ялгыз торып кала. Шулай моңсуланып торганда, аның янына гади генә киемнән Йосыф үзе чыга. «Әйа газиз, кем буласың, кайсы илдән килдең монда, ни кыласың, хаҗәтең ни, ни телисең?» – дип сораштыра башлый. Ибне-Йәминнең күңеле күтәрелеп китә. Озак кына дустанә сөйләшеп торалар. «Кыяфәтең Йосыфка бик охшаган», – ди Ибне-Йәмин. Тик Йосыф әлегә серне ачмый, кыйммәтле беләзек бүләк итә дә, патша сараена юл күрсәтеп, китеп бара.

Ибне-Йәмин шат йөз белән кардәшләре янына килә. Йосыфсыз калганнан бирле елмаюны белмәс энеләренең бу халәтен күреп, бар да гаҗәпләнәләр. «Нидән болай шатланасың?» – дип сорыйлар. Ибне-Йәмин сөйләп бирә, бүләк ителгән беләзеген күрсәтә. Аны тегеләр дә кулларына киеп карыйлар, тик ул берсенә дә ярамый, кире Ибне-Йәмин кулына кайта.

Йосыф кардәшләренең икенче килүенә бик матур сарай салдырып куйган була. Аның диварларына төрле рәсемнәр ясата: «Ягкубның сурәтен һәм янә угланнарының кыяфәтен, аларның Йосыфка

ниләр күрсәткәнен, алдап, аны атасыннан алуларын, коега салуларын, үтерергә аны ният кылуларын...». Бу сарайда Йосыф мәҗлес җыя, барлык кардәшләрен дә чакыра. Ибне-Йәмин янына Йосыф үзе килеп утыра.

Агалары, дивардагы сурәтләргә карап, монда безнең җинаятебез бәян ителгән, дип хафага төшәләр, ашаудан туктыйлар. Моны аңлап, Йосыф аларны башка сарайга алып чыга. Һәммәсе дә ашап-эчә, Ибне-Йәмин генә берни капмас була. «Теге сарайга кереп, сурәтләрне яңадан күрер идем, берсе аның Йосыфка бик охшаган», – ди. Йосыф, ниһаять, Ибне-Йәминне шул сарайда үзенең улы Мөсалим белән очраштыра, серне чиштерә. Туганнар очрашалар, озак кына ялгыз утыралар, елый-елый хәл-әхвәл сорашалар. Күңелләрен бушаталар.

Аерылышыр көн дә килеп җитә. Ибне-Йәмин, Йосыфны янәдән югалтудан куркып, хәсрәткә бата. Агасы аны башкаларга сиздермичә генә үз янында калдыру чарасын таба.

Агалары йөкләренә ашлык төяп кайтыр юлга чыгалар. Йосыф кушуы буенча Ибне-Йәминнең йөгенә алтын касә яшерелгән була. Шәһәрдән чыгып бераз киткәч, боларны куып тоталар, алтын касәне урлагансыз дип, йөкләрен тикшерәләр. Касә Ибне-Йәмин йөгеннән «табыла». Йөк хуҗасын караклыкта «гаепләп», җавапка тарту сылтавы белән Мисырда, газиз агасы янында калдыралар.

Бу хәлләрне ишетеп, Ягкуб карт бик хәсрәтләнә, тагын бер сөйгән углымны югалттым дип кайгыра. «Пәйгамбәр балалары беркемнең дә малын алмас, бозык эшкә бармас, нахакка гаепләнгәндер ул», – дип, Йосыфка хат яздыра. Угыллары янәдән Мисырга китәләр.

...Бер очрашканда Йосыф, сандыктан язу чыгарып, агаларына тоттыра. Бу – агаларының Йосыфны коллыкка сатып җибәргәндә кәрван хуҗасына бирелгән кәгазь була. Тегеләр, эшнең нидә икәнлеген аңлап, язуны танымаган булып кыланалар. Шул вакыт Йосыф йөзеннән пәрдәсен ача. Туганнары, аны танып, өнсез калалар. Йосыф атасы хакына аларның барысын да гафу итә. Ахырда ул туганнарына атасы Ягкубны Мисырга алып килергә куша. Базардан Бәшир исемле бер кол сатып алып, аны алданрак сөенче алырга җибәрә. Исәнлегенә дәлил итеп күрсәтергә күлмәген дә бирә.

Бәширнең анасы кайчандыр Йосыфның тәрбиячесе була. Шул хатынның баласын чит илгә, ятлар кулына сатып җибәреп, Ягкуб зур гөнаһ кыла. Ана зар елый, озак еллар хәсрәт утында яна. Ягкубның сөекле Йосыфыннан җитмеш ел буена аерылып торуы шул гөнаһның җәзасы икән ләбаса!

Бәшир Ягкуб торган авылга килеп җитә. Су буенда кер чайкаучы бер хатынны күреп, Ягкубның өен сорый. Теге хатын, аңа төрле сораулар биреп, үзе турында да сөйләп алырга өлгерә. «Синең углың Бәшир менә мин ул», – дигәч, бичара хатын, сөенеченнән шашар дәрәҗәгә җитеп, газиз баласының кочагына ташлана.

Тиздән Ягкубның уллары да кайтып җитә, шатланышып күрешәләр, хаталарын танып елашалар, кичер безнең гөнаһларны диеп, Аллаһка ялваралар. Гөнаһлар гафу ителә. Барысы да, Йосыфның ихлас чакыруын кабул итеп, дөяләргә төялешеп, Мисырга сәфәр кылырга чыгып китәләр. Йосыф аларны сөенеп каршы ала. Туганнар яңадан кавыша. Олы гаиләдә шатлык, бәхет тантана итә.

Шуның белән Йосыф һәм Зөләйха кыйссасы тәмам була.

## Тагын бераз Кол Гали турында

Кол Галинең кемлеге аның әсәреннән күренә. Ул искиткеч талант иясе генә түгел, ул – беренче нәүбәттә, күп кенә телләр белеп (аның Йосыфы да бит 72 телдә сөйләшә), үзенә кадәр яшәгән Шәрык шагыйрьләренең бөтен иҗатын җентекләп өйрәнгән олы галим дә.

«Кыйссаи Йосыф»ның эчтәлеге, сюжеты бик борынгы дини һәм мифологик риваять-легендаларга нигезләнгән. Бу легендаларның эзләре, аерым алганда, Ягкуб һәм аның улы Йосыф белән бәйләнешле маҗаралар, Коръәндә дә бар икән (12 нче сүрә). Коръәнгә алар яһүд һәм христианнарның изге китаплары булган тагын да борынгырак Тәүраттан һәм Инҗилдән килеп кергән. Шул маҗаралы сюжетка нигезләнеп, инде IV – VI гасырларда ук чәчмә һәм шигъри әсәрләр иҗат ителә башлаган. Һәр автор, элеккеләрен кабатлап кына калмыйча, эчтәлеккә үзеннән дә яңалыклар, кызыклы вакыйгалар өстәгән.

Коръәннең «Йосыф» сүрәсен мөселман илләрендә яшәгән шагыйрьләр, язучылар шул вакытларда бик популяр булган «Кыйссасел әнбия»ләрен, ягъни «Пәйгамбәрләр турында хикәяләр»ен язганда бик теләп һәм иҗади файдаланганнар. Боларның барысы да IX – X гасырларда иҗат иткән бөек Иран шагыйре Фирдәүсинең атаклы «Йосыф вә Зөләйха» исемле зур поэмасы туугa җирлек булган. Йосыфнамә темасын җентекләп өйрәнгән галимнәр, Кол Гали үз әсәрен язганда нәкъ менә Фирдәүсинең шул поэмасына мөрәҗәгать иткән, күп кенә вакыйгаларны шул чыганактан алып язган, диләр. Әлбәттә инде, Кол Гали фарсы шагыйре Фирдәүсине тулысынча кабатламаган, гел аңар гына ияреп бармаган. Кайбер күренешләр халык тормышыннан, җанлы сөйләм телендә йөргән хикәяләрдән килеп кергән.

Кол Гали әсәренең нигезендә төш күрү вакыйгасыннан башланып киткән фаҗигале язмыш – ата һәм угыл мәхәббәте, Йосыфның Ягкубка тугрылыгы турында сөйләүче вакыйгалар ята. Бу инде егет белән кызның мәхәббәт тарихы гына түгел. Эчтәлек күпкә тирәнрәк, киңрәк, баерак. Игътибар иткәнсездер: шагыйрь биредә хөкемдар һәм гади халык бәхете проблемасын да куя. Ул хәтта әсәрнең үзәгендә. Хөкемдар нинди булырга тиеш? Шагыйрь шул сорауга җавап эзли һәм таба. Ул аны әсәрнең төп каһарманы булган Йосыфның кешелек сыйфатлары аша күрсәтә. Йосыф тугрылык, гаделлек, зирәклек, юмартлык, кыюлык һәм батырлык, олы җанлылык, кешеләргә ихтирамлы булу, тыйнаклык кебек гүзәл сыйфатларга ия. Шуңа күрә дә (чибәр булганы өчен генә түгел!) халык аны ярата, үз итә, якын күрә.



Кол Гали. *Бакый Урманче* скульптурасы



«Казанның 1000 еллыгы» паркында шагыйрь Кол Галигә куелган һәйкәл.
Скульпторлары *Андрей Балашов* һәм *Асия Миңнуллина*, архитекторы *Розалия Нургалиева*

Сезгә ничектер, миңа шулай тоела: Кол Гали үзе дә шул сыйфатларга ия булгандыр. Гаделлеккә һәм тугрылыкка, зирәклеккә һәм батырлыкка дан җырлаучы шагыйрьне мин башкача күз алдына китерә алмыйм.

Кол Гали бүген дә онытылмый. Киресенчә, аңа булган кызыксыну көчәйгәннән-көчәя генә бара. «Кыйссаи Йосыф»ны мәктәпләрдә дә, югары уку йортларында да өйрәнәләр. Аның авторын исә Бакый Урманче мәрмәр сында мәңгеләштерде, Нурихан Фәттах «Кол Гали» трагедиясен иҗат итте. Башкалабызның бер урамына Кол Гали исеме бирелде. Казанның 1000 еллыгы көннәрендә барлыкка килгән паркта аңа һәйкәл ачылды. Шагыйрь исеменә багышлап, җырлар, шигырьләр, поэмалар языла. Йосыф белән Зөләйха исә балет сәхнәсендә җанланалар...

Кыскасы, Кол Гали бүген дә безнең белән!

*Кол Гали иҗаты белән тагын да тирәнрәк танышырга теләүчеләр өчен өстәмә әдәбият:*

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында Кыйсса) / төп текстны әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кульязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

*Кол Гали.* Йосыф китабы / Ә. Исхак күчермәсе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.

*Таһирҗанов Габдрахман.* Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.

*Фәттах Нурихан.* Кол Гали: трагедия. Китапта: Фәттах Нурихан. Сайланма әсәрләр: 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 3 т.

*Хисамов Нурмөхәммәт.* Бөек язмышлы әсәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

*Хисамов Нурмөхәммәт.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII – XV йөзләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

# КОЛ ШӘРИФ

Кол Шәриф – сирәк талантлы шагыйрьләребезнең берсе, Казан ханлыгының баш имамы, күренекле дин галиме һәм илче-дипломат. Үзенең бөтен гомерен, талантын, иҗатын халык бәхете өчен фида кылган олы шәхес. Аның исеме татар халкының милли азатлык көрәше тарихында алтын хәрефләр белән уеп язылган. Бу исемне бүген татарлар гына түгел, урыслар да белә. Чит илләрдә дә яхшы таныш ул. Һәрхәлдә, Казанга килеп киткән чит ил туристлары Кол Шәриф исемен бик тиз отып алалар – әйтергә уңайлы, матур яңгырашлы. Бөтен Рәсәйдәге иң матур мәчет тә шушы атаклы шәхес исемен йөртә. Кол Шәриф исемен көн саен йөзәрләгән, меңәрләгән кеше кабатлый.

Әйе, Кол Шәриф – халык телендә. Әмма аның турында без нәрсәләр беләбез соң? Ни кызганыч, мәгълүматларыбыз бик аз. Шулай да аның тормыш юлын, иҗатын һәм эшчәнлеген бераз күзалларга мөмкин.



## Кол Шәрифнең тормыш юлы

Аның кайчан һәм кайда туганы төгәл генә билгеле түгел. Кырымда яки Хаҗи Тарханда (Әстерханда) туган булырга тиеш дип фаразлыйлар. Һәрхәлдә, Кол Шәрифнең Казанга күчеп килгәнче Хаҗи Тарханда яшәгәне мәгълүм (тәхәллүсе дә очраклы гына түгел бит – Хаҗитархани). Аның атасы Хөсәен (кайбер мәгълүматлар буенча – Мансур) исемле булган. Сәетләр нәселеннән. Сәет дип ул вакытларда нәсел җепләре Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташкан дин әһелләрен атаганнар. Алар дәүләт идарәсендә зур урын биләп торганнар. Алтын Урдадан соң барлыкка килгән ханлыкларда берничә сәет булып, аларның берсен, акылына һәм белеменә карап, әлбәттә, олуг сәет итеп сайлаганнар. Безнең көннәргә кадәр сакланган бер шәҗәрәдә, Кол Шәрифнең атасы Хөсәен Әстерханда сәет булып

Кол Шәриф.
Рәссам *Надия Фәхретдинова* картинасыннан репродукция



Урта гасырлар Казаны.
Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция

торган дип күрсәтелә. Кол Шәриф үзе дә Казан ханлыгы чорына караган документларда сәет дип язылган. 1551 елның октябреннән башлап рәсми рәвештә олуг сәет вазифасын башкарган. Бу инде – дәрәҗәсе ягыннан ханнан кала икенче урында торучы бик зур дәүләт эшлеклесе дигән сүз.

Кол Шәрифнең абруе турында документлар болай сөйли: ул, гадәттә, ак атына атланып, Казан урамнарында йөрергә яраткан. Гади шәһәр халкы хөрмәт йөзеннән аны бил бөгеп сәламләгән. Хәтта Сафа Гәрәй хан үзе дә, Кол Шәриф белән очрашканда, атыннан төшеп, аның чапан итәген үбеп, хәл-әхвәл сорашып, сәламәтлек теләп киткән. Урыс кенәзләре исә аңа махсус хатлар юллаганнар, илчеләре аша бүләкләр биреп җибәрә торган булганнар.

Кол Шәрифнең дәүләт эшлеклесе буларак кылган гамәлләре турында бик аз беләбез. Шунысы гына төгәл мәгълүм: аңа татар дәүләтенең, башкалабызның язмышы кыл өстендә торган иң авыр һәм катлаулы заманда эш итәргә туры килә. Уйлап карагыз: урыс гаскәрләре Казанга кадәр килеп җиткәннәр. Зөя тамагында бер ай эчендә, казанлыларга сиздермичә генә, көчле крепость – хәрби ныгытма калкып чыга. Тау ягы халкы Явыз Иванга тугры булырга ант бирә, димәк, аңа буйсындырыла, җирләре Казаннан тартып алына. Башкаланың үзендә исә Сөембикә хөкүмәте соңгы сулышын алырга җыена. Шундый шартларда 1551 елның июнендә хөкүмәткә Ходайкол углан белән Нурали Ширин җитәкчелегендәге төркем килә. Чарасызлыктан Зөя каласында урнашкан урыслар үзләре арасында йөрүче сатлыкҗан Шаһгали белән сөйләшүләр башлый.

Казан ягыннан илчелек җитәкчеләре итеп Кол Шәриф сәет һәм кенәз Бибарс Растов билгеләнә. Ике арада шартнамә төзелә. Казанлылар бик авыр хәлдә калалар. Шартнамә нигезендә Казан хөкүмәте тәхеткә Шаһгалине утыртырга, Сөембикә белән аның улын – ике яшен яңа тутырган Үтәмеш Гәрәй ханны кулга алып Мәскәүгә озатырга, Казандагы урыс әсирләрен азат итәргә тиеш була. 1551 елның 11 августында Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәйне тоткынлыкка озаталар. 14 августта җыелган корылтайда элегрәк төзелгән шартнамәне яңадан бер мәртәбә раслыйлар. 16 августта Казан тәхетенә Шаһгали утыра. 17 августта урыс әсирләрен иреккә чыгара башлыйлар.



Корылтай.
Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция

Шаһгали хан булып озак утыра алмый. 1552 ел башында Явыз Иван, аны хан дәрәҗәсеннән мәхрүм итеп, Казанга үзенең урынбасары рәвешендә кенәз Семен Микулинскийны җибәрә. Барысы да аңа тугрылыкта ант бирергә мәҗбүр ителәләр. 9 мартта ул тантаналы рәвештә Казанга керергә тиеш була. Әмма аңа шәһәр капкасын ачучы булмый. Кенәз кире Зөя крепостена кайтып китә. Димәк, Казанны, Иван патша уйлаганча, тыныч юл белән, сугышсыз гына кулга төшереп булмаячак!

Казанлылар исә хөкүмәт башына Чапкын Отучевны утырталар. Хөкүмәт составына олуг сәет Кол Шәрифне дә кертәләр. Үзенең төп максаты итеп Чапкын Отучев ханлыкның мөстәкыйльлеген саклап калуны куя. Хан итеп Әстерханнан Ядегәр исемле угланны чакыралар.

Казанны сугышып алу өчен Мәскәүдән 150 меңлек яхшы коралланган гаскәр чыга. Август аенда алар Зөя каласына килеп җитәләр. Биредән Шаһгали – Ядегәр ханга, ә Иван патша үзе Кол Шәрифкә хат белән мөрәҗәгать итәләр. «Казанны сугышмыйча гына бирегез» дигән таләп куялар. Әлбәттә, ул таләп бертавыштан кире кагыла.

Август ахырларында урыслар Казанны бар яктан да камап алалар. Аталык һәм Төмән капкалары арасына, җирне казып,



Казан Кремлендә Төмән манарасы

дары тутырылган мичкәләр куела. Кремль стеналары артына сыенган Казан халкына тагын бер тапкыр мөрәҗәгать итеп карыйлар: исән каласыгыз килсә, каршылык күрсәтмәгез, безнең белән солых төзергә риза булыгыз! Казанлылар солых турында ишетергә дә теләмиләр.

4 сентябрьдә беренче шартлау яңгырый. Күпләгән кеше һәлак була, ләкин шәһәрне саклаучылар бирелмиләр. Ай буена диярлек өзлексез сугыш бара.

«...Кол Шәриф йокламый, йоклый алмый. Дөньяны борчулы уйлар басты. Алар тынгылык бирми, көнен дә, төнен дә миен бораулый, ике чигәсен авырттырып кыса, диван әһелләреннән, бөтен ханлыкның акыл ияләреннән ала алмаган җавапны каян табарга кирәклеген эзләп бәргәләнергә мәҗбүр итә. Бабаларыбызның сыеныр, туеныр урыны – газиз җиребезне, ил-көнебезне, Аллаһы Тәгалә рәхмәте илә Мөхәммәд галәйһиссәламгә сыенган илдәшләребезне ни көтә?!

Йа Алла! Сабырлык, түземлек бир! Белгәнеңне, сизенгәнеңне теш арасына кысып чыдарлык көч бир!» (*Флүс Латыйфи*)

Кол Шәриф Казан халкы өстенә килгән афәтнең коточкыч зур булуын күңеле белән сизә. Аны нишләргә дигән сорау борчымый. Әлбәттә, халкы белән бергә булырга, ватандашларын изге сугышка рухландырырга! Кирәк икән, үзе дә соңгы сулышына кадәр көрәшәчәк, әмма кол булмаячак!

Фаҗига ахырына якынлаша. 1 октябрьдә урыс гаскәрләренә соңгы штурмга әзерләнергә әмер килә. Шәһәрне саклаучыларга һичнинди каршылыксыз бирелергә ультиматум – кискен таләп куела. Казанлылар горур рәвештә: «Буйсынмыйбыз, диварларда һәм башняларда Русь тора. Ләкин без икенче дивар салырбыз, барыбыз да һәлак булырбыз яисә крепостьта сакланып калырбыз!» – дип җавап бирәләр.

2 октябрьдә Аталык капкасы янында колак тондыргыч көчле шартлау ныгытмаларның бер өлешен юкка чыгара. Ташлар, кешеләр, бүрәнәләр,



Казанны алу. 1552 елның 2 октябре. Рәссам *Карл Вениг* картинасыннан репродукция



Кол Шәриф мәчете янында соңгы сугыш. Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция

жир кантарлары – барысы да күккә оча. Шәһәрне саклаучылар аңга килергә өлгергәнче, тагын да катырак икенче шартлау яңгырый.

Яуды аска уклар...
Атылды таш...
Акты су һәм кайнар сумала...
Изге жир бу!
Анда ансат кына
Бил бирер зат әле тумаган!

*Әхмәт Рәшит*

Урыс гаскәрләре кара болыт булып Кремльгә ябырыла. Урам сугышлары башлана. Туплар гөрелдн, уклар сызгырып оча. Казанлылыр нык торалар, әмма көчләр тигез булмый, әкренләп артка чигенәләр.

Соңгы бәрелеш крепость үзәгендә, Кол Шәриф мәчете янында бара. Кулларына ни туры килсә шуның белән коралланган бер төркем мәдрәсә шәкертләре, муллалар, абызлар басып алучыларга каршы һөҗүмгә күтәрелә. Араларында куркып дошман каршында тез чүгәргә маташучылар юк. Сугыш мәйданына кулына кылыч-калкан тоткан Кол Шәриф үзе чыга. Моны күреп, шәкертләре тагын да кыюланып китәләр, тешләре-тырнаклары белән дошман өстенә ыргылалар. Күпләре һәлак була. Исән калганнары, Кол Шәриф сәеткә ияреп, сугыша-сугыша, мәчет ягына чигенәләр. Көрәшнең соңгы минутлары, халык арасында сакланып калган риваятьләрдә әйтелгәнчә, мәчет түбәсендә бара...

Казан җиңелә. Әмма Кол Шәрифнең һәм ул тәрбияләп үстергән яшь шәкертләрнең искиткеч батырлыгы безнең күңелләрдә бүген дә соклану уята. Мондый каһарманнарны халкыбыз мәңгегә онытмас!

## Кол Шәриф иҗаты

Халкыбыз күңелендә Кол Шәриф үзенең илһамлы шигърияте, рухи бөеклеккә өндәүче әсәрләре белән дә урын алган. Кызганыч, аның бүгенгә кадәр сакланып калган әсәрләре бик аз: безгә аның бары дүрт-биш шигыре, шул исәптән «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» исемле зур күләмле поэмасы һәм дә «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» («Казан иленең җиңүе») дигән чәчмә әсәре генә билгеле. Аның иҗади

Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчете



мирасы болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Барланмаган әле ул, тулысынча өйрәнелмәгән.

Кол Шәрифне әдәбият белгечләре суфи шагыйрьләр рәтенә кертәләр. Кол Шәриф үзенең остазлары итеп XII гасырда Урта Азия якларында яшәп иҗат иткән бөек шәхес Әхмәт Ясәвине һәм аның шәкерте Сөләйман Бакырганыйны саный. Аларның әсәрләре Казан ханлыгы чорында безнең якларда да бик киң таралган була.

Шигырьләрендә Кол Шәриф Аллаһы Тәгаләгә дан җырлый, аны олыларга өнди, фани дөньяда намус белән, нәфескә бирелмичә яшәп, Алла каршына гөнаһсыз булып барырга чакыра.

Галимнәр Кол Шәрифнең башка әсәрләре дә табылыр дигән өмет белән яши. Эзләнүләр дәвам итә.




Кол Шәриф безгә яңадан кайтты. Казан Кремлендә башкалабызның 1000 еллык юбилеена әзерлек көннәрендә ачылган мәһабәт мәчет олуг шәхесебезнең исемен мәңгеләштерде, аны бүгенге яшәешебезнең аерылмас өлешенә әверелдерде.

*Кол Шәрифнең тормышы һәм иҗаты белән кызыксынучыларга өстәмә әдәбият:*

*Кол Шәриф*. И күңел, бу дөньядыр...: газәлләр, кыйсса / җыентыкны төзүче һәм кереш сүз авторы Ә.Шәрипов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

Кол Шәриф һәм аның заманы / Кул Шариф и его время. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

Кол Шәриф мәчете. Керү урыны

# СӨЕМБИКӘ

Татар халкын Сөембикәсез күз алдына китереп булмый. Халкыбыз күңеленә бик тирән кереп урнашкан ул. Сөембикә – татар халкының милли азатлык һәм мөстәкыйльлек символы, диләр. Бу чыннан да шулай – ачы тарихыбызның хәсрәтле күз яшьләрен дә, киләчәккә бәйләнешле өмет-хыялларын да сыйдырган аның язмышы.

Сөембикәне һәркем үзенчә күз алдына китерә, үзенчә олылый, хөрмәтли, якын күрә. Һаман да юксына, сагына.

## Нугайлар

Без, Кол Гали белән Кол Шәрифкә караганда, Сөембикә турында күбрәк беләбез, әмма барыбер җитәрлек дәрәҗәдә түгел.

...Түбән Идел белән Җаек (хәзерге Урал елгасы) арасында, аннан соң тагын да ераграк, көньяк-көнчыгыш тарафка китеп Арал диңгезенә кадәр сузылган иксез-чиксез далаларда нугай кабиләләре яшәгән. Кардәшлек ягыннан караганда, алар кыпчакларга бик якын торганнар. Юлбашчылары кайчандыр, әле XIII йөздә үк, Алтын Урданың Нугай исемле әмире – Җүчи ханның оныгы булган. Соңыннан аңа буйсынган халыкларны нугайлар дип йөртә башлаганнар, имеш.

Бу якларда яңгырлар хәтта көзләрен дә сирәк ява, эссе җәй урталарында исә кечкенә елгачыклар, күлләр бөтенләй диярлек кибеп-корып бетә. Урманнар юк та юк инде, үзәнлекләрдә генә аратирә вак-төяк әрәмәлекләр, куаклыклар очраштыргалый. Арал диңгезенә җитәрәк ул далалар да әкренләп ярымчүлгә, аннан соң комлы чүлгә әвереләләр. Табигать шартлары игенчелек белән шөгыльләнү өчен һич яраклы түгел. Шуңа күрә нугайлар күчмә терлекчелек белән көн күрәләр. Байлыклары – ат, дөя, куй көтүләре. Ел әйләнәсе, уңайлы көтүлекләр эзләп, бер урыннан икенче урынга күченеп йөриләр. Үзәнлекләрдә гадәттә кечкенә сулыклар, чишмәләр була. Андый урыннарда кышкы ялга туктыйлар. Дистәләгән һәм йөзләгән тирмәләрдән гыйбарәт олы бер авыл хасил була. Кыш үтеп яз җитүгә, ул авыллар яңадан «күчеп китәләр».

Сирәк кенә булса да, әлеге кышлакларның кайберләре, уңайлы урында, су буенда утырганнары, чын шәһәрләргә әверелгәннәр. Сарайчык, мәсәлән, шундыйлар исәбеннән. Җаекның түбән агымында, Каспий диңгезенә килеп җитәрәк барлыкка килгән бу шәһәр нугайларның, дөресрәге, тарихка Нугай Урдасы исеме белән кереп калган дәүләтнең башкаласы була.

Нугай Урдасы – XIV йөзнең ахырында таркала башлап, XV йөзнең башларында мөстәкыйль дәүләт буларак яшәүдән туктаган Алтын Урданың бер өлеше ул. Хакимнәре – мәшһүр Идегәй нә-



Сөембикә.
Рәссам *Нияз Хаҗиәхмәтов* картинасыннан репродукция

селеннән чыккан бәкләр (Чыңгыз токымыннан булмагач, нугайларда ханнар булмый). XVI йөзнең беренче яртысында Нугай Урдасы зур гына дәүләт була. Тарихчы-галимнәр, халкының саны 1 миллионга җиткән, диләр. Хәтта Казан ханлыгында да бу кадәр халык яшәмәгән.

Нугай бәкләре Казан ханнары белән аралашып көн күргәннәр. Җәйге көтүлекләре дә Урта Иделгә – хәзерге Самара дугасына кадәр килеп җиткән. Нугайларның кайбер төркемнәре Каманың түбән агымына кадәр булган җирләрне үзләштерә башлаганнар. Дөрес, кыш җитүгә, алар яңадан үзләренең көньяк далаларына кайтып киткәннәр. Әмма арада гомерләр узу белән безнең төбәккә яраклашып, аны үз итеп, бөтенләйгә торып калучылары да булмаган түгел.

Казан халкы белән нугайлар арасында мөнәсәбәт ничектер үзгәрәк була. Казан – болгарлар дәүләте чорында ук салынган борынгы кала. Тәхеттә кайчандыр Алтын Урдада хан булып торган мәшһүр Олуг Мөхәммәднең турыдан-туры варислары утыра. Мәскәүнең олуг кенәзләре, хәтта патшалары алардан куркып торалар. Шулай булгач, нугайлар туганнары белән тыныч кына яшиләр.

Әмма нугай бәкләре, үсеп баручы көч-куәтләрен сизеп, Казан, хәтта Мәскәүнең сәяси эшләренә катнаша башлыйлар, кайчак хәрби көч куллану белән дә яныйлар. Мәсәлән, 1496 елда Казан тәхетенә нугайлар теләге белән һәм аларның басымы астында ерак Себердән Мамук ханны, 1546 елда Кырымнан Сафа Гәрәйне утырталар.

Казан ханнары белән нугай бәкләре арасында никах бәйләнешләре дә гадәти хәлгә әверелә. Бусы инде ике як өчен дә



Казан ханнарының тәхете

файдалы була. Башта Тимур бәкнең кызы Нурсолтанны Казанга, Хәлил ханга кияүгә бирәләр. Аның вафатыннан соң, Нурсолтанны, борынгы йола буенча, Ибраһим хан – Хәлилнең бертуган энесе хатынлыкка ала. Аннан соң Мөхәммәд Әмин хан Муса бәкнең кызы Фатыймага өйләнә. Муса бәкнең олы углы Йосыф морза – Сөембикәнең атасы. 1549 елда ул бәк дәрәҗәсенә ирешә, Казан тарихында мәгълүм шәхес була.

## Сөембикәнең яшьлеге

Сөембикәнең Йосыф морза гаиләсендә дөньяга килүе – документлар белән расланган факт. Кайчан туган? – бусы бәхәсле мәсьәлә, чөнки бер генә документта да аның туган елы күрсәтелмәгән. Гадәттә, «1516 еллар тирәсендә» дип язалар. «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә дә шул дата куелган. Мин үзем танылган дин белгече һәм тарихчы галим Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтләрендә китерелгән 1519 ел датасын дөрес дип саныйм. Танылган фольклорчы галим, профессор Фатих ага Урманче үзенең Сөембикәгә багышланган бер хезмәтендә аның туган елын «1519, төгәлрәге 1520» дип күрсәтә.

Сөембикәнең бала чагы, үсмерлек еллары Нугай далаларында үтә. Бик тә кадерле бала була ул гаиләдә. Барысы да аны ярата, иркәли – сабый чактан ук бик чибәр, сөйкемле, акыллы кыз була шул ул. «Андагы кебек чибәрлекне Казан кызларында гына түгел, Мәскәүнең бояр һәм кенәзләренең хатын-кызлары арасында да очрату кыен булган», – дип яза тарихчы галимнәр. Язучылар аны үзенчә тасвирлый: «Нурлы йөз вә нурлы, сихерле, берникадәр дымсу кара күзләр, әле генә пешеп җиткән вә таң чыгына яисә ләйсән тамчыларына эләккән чиядәй иреннәр, чем-кара каш, шундый ук чәчләр, илаһи бер осталык белән яратылган төз, сылу гәүдә... Ерак Мисыр, Бохара, Үргәнеч, Чин-Мачин якларыннан килгән затлы ефәктән тегелгән, челтәрле балитәкләр белән бизәлгән, гүзәл тәненә сыланып торган күлмәк, аның өстеннән киелгән шундый ук затлы камзул. Башында сусар тиресеннән тегелгән түбәтәй вә кызыл яулык. Морза кызы булган Сөембикәнең киемнәре, бигрәк тә туй-бәйрәм көннәрендә, төрле яклардан, төрле илләрдән килгән алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, башка бик күп төрле асылташлар белән бизәлә иде».

Чибәрлек туйда кирәк, ди. Гүзәлләрнең гүзәле булудан тыш, Сөембикәгә генә хас башка сыйфатларны да әйтеп үтәргә кирәктер. Холкы – ирек сөючән, горур. Көчле рухлы, каһарман хатын. Бу сыйфатлары да аның табигатьтән килә, «иксез-чиксез Нугай далалары, Җаек суы, җәйге эссе кояш һәм зәңгәр күк белән бәйләнгән». Әйе, гомер буе дала-кырларда, мәрхәмәтле дә, кырыс та табигать кочагында күченеп йөргән нугай халкының төп сыйфаты – бернәрсә белән дә чикләнмәгән азатлыкка вә иркенлеккә омтылыш. Бу сыйфат аларда ата-бабадан килгән, гасырлар буена эзлекле тәрбияләнеп, халыкның асыл сыйфатына әверелгән. Сөембикәнең дә иркенлек, азатлык сөюе, гомер буе беркемгә дә буйсынырга теләмичә яшәве – туган халкының холкы-табигате чагылышыдыр.

Элек-электән шулай килгән: ил башында торучылар кызларын-улларын шундый ук дәрәҗәле

кешеләрнең балалары белән никахландырганнар. Үзенә күрә бер сәясәт булган ул. Хакимнәр туганлашкан, димәк, алар идарә иткән ил-дәүләтләр арасында сугышлар булмаган, тынычлык, дуслык, хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнашкан.

Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасы – тамырлары белән Алтын Урдага барып тоташкан тугандаш илләр. Халыклары ислам динен тота. Ханнар һәм бәкләр нәселендәге туган-тумачалык та күптәннән килә. Сөембикәне дә шундый бәхетле язмыш көтә кебек тоела. Әмма язмыш аңа бик күп сынаулар әзерләп куйган булып чыга.

...1445 елда барлыкка килгән Казан ханлыгы бары тик 1487 елга кадәр генә бар яктан да мөстәкыйль, куәтле дәүләт булып яши. 1487 елда Казанны урысларның бөек кенәзе Иван III гаскәре камап ала. Илһам ханны кулга алалар һәм Вологдага сөргенгә озаталар. Ханлык, мөстәкыйльлеген бөтенләй үк югалтып бетермәсә дә, Русь бәйлелегенә эләгә. Иван III Болгар кенәзе дигән титул ала. Яңа хан Мөхәммәд Әмин Мәскәүгә каршы сугышмаска һәм һәркайда урыс кешеләренең мәнфәгатен якларга йөкләмә ала. Казанда исә сәясәтчеләрнең ике төркеме барлыкка килә: Мәскәү яклылар төркеме һәм урыс кенәзенә каршылар төркеме. Алар арасында гел тарткалаш бара, тәхеткә әле бер төркем, әле икенче төркем тарафдарлары килә.

1518 елда каты авырудан соң Мөхәммәд Әмин хан вафат була. Мәскәү Казан тәхетенә үзенә тулысынча бәйле Касыйм ханлыгыннан 13 яшьлек Шаһгалине тәкъдим итә.

Шаһгалине Казанда берәү дә яратмаган, шуңа күрә ул аз гына вакыт идарә итәргә өлгергән. Һәрдаим Мәскәүне яклап эш йөртүе белән яшь хан халыкның ачуын чыгарган. Казанлылар Кырым ханына мөрәҗәгать итәргә булганнар. 1521 елда шәһәргә Сәхиб Гәрәй җитәкчелегендәге Кырым гаскәрләре керә. Шаһгали тәхеттән куыла. Казанның Мәскәүдән бәйлелеге шуның белән тәмамлана. Әмма урыслар Казан эшләренә тыкшынудан туктамыйлар.

Сәхиб Гәрәй Казанда өч ел чамасы гына хакимлек итә. 1524 елда ул, үз урынына 13 яшен тутырган туганы Сафа Гәрәйне калдырып, ягъни аны хан итеп, үз теләге белән Кырымга кайтып китә. Урысларның яңа кенәзе Василий III Сафа Гәрәйне законлы хан итеп таный. Үсеп ирегет булгач, акыл кергәч, Сафа Гәрәй күрә: Мәскәү Казанны һаман үз кубызында биетергә чамалый. Бу аның рухына туры килми. Казан халкы кайчан урыс акылы белән яшәүдән туктар? Яшь хан киләчәктә ике арада кискен көрәш булачагын аңлый. Казанны өстәмә ныгытмалар белән уратып ала. Хәрби флот төзү эшенә керешә. Василий III бу тамашага тыныч кына карап тормый, Казанга сугышлар белән килә. Тыныч



Җиз кувшин. Мөхәммәд Әмин хан вакытында
Насыйр исемле оста тарафыннан ясалган. XVI йөз башы

вакытта исә, Мәскәү яклылар төркемен баш күтәрергә өндәп, шымчылар ярдәмендә астыртын эш алып бара. Нәтиҗәдә 1531 елда Сафа Гәрәй тәхеттән куыла. Казан тәхетенә Мәскәү тәкъдиме белән Касыймнан килгән яңа ханны утырталар. Ул Шаһгалинең бертуган энесе Җангали була.

Шулай итеп, дуслар, Казан ханлыгының сәяси тарихына кыскача гына күзәтү барышында сез Сөембикәнең Казандагы тормышында иң зур роль уйнаган өч шәхес белән очраштыгыз. Болар – Җангали, Сафа Гәрәй һәм Шаһгали. Өчесе дә төрле елларда Казан ханы булып торган шәхесләр. Өчесе дә Сөембикәнең никахлы ирләре. Нугай сылуының бәхете дә, фаҗига дәрәҗәсенә җиткән бәхетсезлеге дә алар аркасында була.

## Сөембикә һәм Җангали

Җангали 1516 елда туа. Ягъни ул Сөембикәдән өч яшькә олырак була. 15 яшендә аны Казан тәхетенә утырталар. Ниндирәк хан булган соң ул малай? Фаразларга мөмкин. Тагын бер тапкыр аның татар тарихына бары тик тискәре шәхес, сатлыкҗан буларак кереп калган Шаһгалинең бертуган энесе булуын искә төшерик. Икесе дә Шәех-Аллаһияр хан малайлары (шул да мәгълүм булсын: әниләре – нугай бәге Ибраһимның кызы Шаһи-Солтан), тумышлары белән Касыйм шәһәреннән. Касыйм ханлыгы исә 1445 елда Мәскәү кенәзе Василий II тарафыннан казанлыларга каршы көрәш максатында урыс җирендә (хәзерге Рязань өлкәсендә) төзелгән курчак дәүләт. Шулай булгач, бар да аңлашыла: урыс кенәзләре туендырып торган Касыйм ханнары Казан мәнфәгате өчен көрәшмиләр, киресенчә, Мәскәү ягын кайгыртталар.



Җангали дә шундыйлардан була. Ул Казан тәхетендә бераз утырып алган абыйсының сүзеннән чыкмый. Мөстәкыйль сәясәт алып бару өчен әле бик яшь була. Ә Мәскәү кенәзе бик мәкерле эш йөртә. Аның максаты бер генә була: Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән ханлыкларны үзенә буйсындыру. Аларны киләчәктә мәңгегә юкка чыгару өчен, Мәскәү Касыймнан китереп утыртылган Җангали аша Казан белән үзе теләгәнчә идарә итә ала. Әгәр дә аны берәр нугай сылуына өйләндереп куйсаң?.. Әйе, Нугай Урдасына да Казан аша юл салырга мөмкин. Ә нугайлар Кырым ханнарын беркайчан да үз итмиләр, гел сугышып

Җангали.
Рәссам *Рушан Шәмсетдинов* картинасыннан репродукция



Сөембикәнең Казанга килүе.
Рәссам *Фиринат Халиков*
картинасыннан репродукция

торалар. Мәскәү өчен ике туганны үзара сугыштыру файдалы була. Сугышларда хәлсезләнгән Кырымны тизрәк кулга төшерү мөмкин булачак бит.

Үсмер кыз Сөембикә үзе болар турында белми, әлбәттә. Әмма аның язмышы шул сәясәт белән бәйләнгән булачак.

1533 елда Җангалинең Йосыф бәк кызы Сөембикәгә өйләндерү мәсьәләсен хәл итү өчен Мәскәүгә махсус илчеләр җибәрелә. Уңай җавап алына. Шул ук елны, нугайларда туй мәҗлесе үткәрәләр һәм яшьләр Казанга кайта.

Бөтенләй яңа тормыш башлана. Бер яктан кызык та кебек. Казан – гүзәл, бай кала. Искиткеч матур. Биек таш йортлар. Манаралары күккә ашкан мәчетләр. Хан сарае. Әмма ничектер шомландыргыч. Эч пошырганы шул – Сөембикә монда үзен бик-бик ялгыз хис итә. Аны аңлаучы да, күңелен юатучы да булмый.

Сөембикә – бик күзәтүчән, үткен, эшнең асылына тиз төшенүчән бикә була. Беренче күрүгә үк Җангалине нигәдер ошатмый. Артык яшь булгангадыр, бәлки? Юк, хыялындагы егеткә һич тә охшамаганга. Казан тиклем Казанның ханы бик тә горур, һәр сүзен үлчәп сөйли торган, акыллы һәм... үз кул астындагы түрәләрнең котын алып торырлык гайрәтле һәм каты куллы ир булырга тиеш булганга. Ә Җангали – беркатлы һәм җебегән бер кемсә. Йомшак холыклы. Үз шәүләсеннән үзе куркып йөри. Тирә-юнендә барлыкка килгән ике капма-каршы төркемнең үзара көрәшен дә күрми, күрсә – аңламый. Югыйсә дошманнарының көннән-көн артуын һәм көчәюен күреп тора ич. Моның өчен артык акыл кирәк түгел. Әнә, хөкүмәт башында торучы Гәүһәршад (Ибраһим хан кызы, Мөхәммәд Әмин ханның сеңлесе) һәм аның яраннары Булат Ширин белән Табай бәкләр ни кыланмый? Аларның һәркайда сүзе үтә, чынбарлыкта ил белән хан түгел, алар идарә итә. Ахыры хәерле булмастыр моның. Җангалинең ил-дәүләт өчен бер файдалы гамәл кылганы юк бит әле. Кыла да алмас, чөнки Мәскәү ни кушса, тик шуны эшләп ята. Бәкләр-морзалар даирәсендә таянычы юк дип уйлый Сөембикә.

Шулай булып чыга да. 1535 елның 25 сентябрендә Җангалине Казансу буенда үтереп ташлыйлар. Халык арасында «бу Булат Ширин оештырган эштер» дигән сүзләр йөри. Бәлки, шулайдыр да, ничек булганын бер Алла белә.

Сөембикә өчен дә күңелле хәл булмый. Тик ханбикә моңа артык борчылмагандыр кебек. Ни өчен дигәндә, Җангали белән аның арасында чын мәхәббәт булмаган, диләр. Бу турыда кайбер язма чыганакларда хәбәрләр дә бар. Имеш, Җангали белән киеренке мөнәсәбәтләре, иренең аны тыңламавы, кирелеге, түбәнсетеп каравы хакында Сөембикә атасына үзе язып җибәргән. Хатта язылганнар хәтта Мәскәү кенәзенә барып ирешкән... Ничек кенә булмасын, Җангали белән Сөембикә бәхетле тормыш кичергәндер дип әйтә алмыйбыз. Сөембикәбез бар яктан да – зирәк акылы белән дә, холкы-табигате белән дә – Җангалидән өстен булып чыга.

## Сөембикә һәм Сафа Гәрәй

Җангалинең фаҗигале үлеменнән соң Казан тәхетенә яңадан Сафа Гәрәйне чакыралар. Бу хәл 1536 елда була.

Кайбер язма документларга караганда, Сафа Гәрәй 1510 елда туган. Димәк, икенче тапкыр Казан тәхетен яулаганда, аңа 26 яшьләр чамасы була. Өйләнгән. Дүрт хатыны бар. (Ул заман өчен гадәти күренеш.) Хатыннарының берсе – нугай морзасы Шәех-Мамай кызы. Сафа Гәрәй хан булуга, Казан түрәләре аңа Җангалидән яшьли тол калган Сөембикәне димлиләр. Йола шулай куша. Ата-бабаларының гореф-гадәтен белгән Сөембикә моңа күңеле белән әзер һәм риза була.

Сөембикә белән Сафа Гәрәйнең саф мәхәббәте легендаларга кергән. Ул мәхәббәт беренче күрешүдән үк башлана һәм геройларыбызның соңгы көннәренә кадәр дәвам итә.

Сафа Гәрәй бар яклап та Җангалинең киресе булып чыга: кыю һәм тәвәккәл, табигать биргән акылы бар, үз сүзен сүз итә алырдай көчле рухлы, гайрәтле ир. Тагын бер өстенлеге бар: ул Мәскәүдән еракта туып үскән һәм тәрбияләнгән. Җангали кебек, Мәскәү патшалары өчен җан атмаган, Казан халкы өчен тырышкан.

Сөембикә тарихын җентекләп өйрәнгән галимебез Фа-



Никах.
Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция



Казан ханнарының таҗы

тих Урманче болай дип яза: «Көнчыгышта элек-электән гадәти бер эш булган хәл кабатланды: анда хан, падиша һәм башка хөкемдарлар ил язмышын үзләре генә түгел, хатыннары белән бергәләп хәл итә торган булганнар. Ике урынлы тәхетнең бер ягында хөкемдар үзе, икенче ягында аның хатыны булып, җитди мәсьәләләрнең барысын бергәләп хәл иткәннәр. Шул рәвешчә, Казан ханнарының иң күренеклеләреннән булган Сафа Гәрәй белән Сөембикә Шәрык илләрендә бик борынгыдан килгән матур йоланы яңадан Казан җирлегендә торгызалар кебек».

…Сафа Гәрәйнең икенче идарә чоры шактый уңышлы башлана. Казанның югары катлау әһелләре йогынтысында ул Мәскәүдән дә, Кырымнан да бәйсез сәясәт тотарга омтыла. Ләкин Мәскәү хөкүмәте Казанга дәгъвасыннан баш тартмый. Хәер, Кырым ханы да Казан җирен үзенеке дип саный.

Сафа Гәрәй рус җирләренә яу чаба, Түбән Новгород, Муром, Кострома тирәсендәге шәһәр һәм авылларны туздыра башлый. Мәскәүдә бу вакытта инде тиздән «Явыз» («Грозный») кушаматы алачак Иван IV идарә итә. Җавап йөзеннән ул да сугышка әзерләнә башлый, Казанның Мәскәүдән элеккеге – Мөхәммәд Әмин һәм Җангали чорындагы бәйлелеген кайтарырга ниятли. Кырым ханы Сәхиб Гәрәй – Сафа Гәрәйнең абыйсы – бу хәлләрне ишетеп, Мәскәүгә хат яза, Иван IV Казанга сугыш белән килгән очракта, урыс җирләренә басып керәчәген әйтә. Бу шартларда Сафа Гәрәй Кырым яклы булырга карар итә. Кырымнан чыккан кешеләрне үз тирәсенә туплый, казанлыларга ышанып җитми.

Казан түрәләре тагын үзләренең кемлекләрен күрсәтеп алалар – Сафа Гәрәйгә каршы астыртын көрәш башлыйлар. 1541 елда хөкүмәт башында торучы Булат Ширин, Гәүһәршад ризалыгы белән Мәскәүгә илчеләр җибәрә. «Мәскәү патшасы Казанга үзенең гаскәрен җибәрсен, бергәләп кырымлыларны куып җибәрербез, Сафа Гәрәйне кулга алып, сезгә тапшырачакбыз», – дип белдерә илчелекнең башлыгы Чабык морза. Сугышка әзерлек башлана, әмма ул әлегә булмыйча кала, Мәскәүнең үзендә хәлләр катлауланып китә.

Мәскәү яклы, үзенә каршы торучы Казан түрәләренә Сафа Гәрәй каты бәрелә: кайберләрен хәтта хыянәттә гаепләп, җәзалап үтертә һәм, бер документта язылганча, «күп кенә кенәзләрнең малмөлкәтләрен талап ала, байлык туплап, аны Кырымга җибәрә». Казанлылар моны, Сафа Гәрәй безне хокукларыбыздан мәхрүм итәргә җыена, дип бәяли.

Ни генә булмасын, әкренләп тынычланалар. Мәскәү дә әлегә комачауламый. Сафа Гәрәйнең Казан өчен нык торуын, аның кырыс холкын сизеп алганнардыр, күрәсең. Сөембикә белән дә матур гына тормыш алып бара ханыбыз. Дөрес, башка хатыннарыннан бөтен уңай яклары белән аерылып



Хан сараенда ишек сакчысы.
Рәссам *Нияз Хаҗиәхмәтов* картинасыннан репродукция

торган сөйкемле Сөембикәгә күбрәк игътибар бирелә. Аның янында күбрәк булырга тырыша. Әйе, яшь хатыны зирәк акыллы була, хан тәхете тирәсендә барган хәлләрнең асылын тирәнтен аңлый, шуңа күрә кайчакта файдалы киңәшләрен дә биреп тора. Бар да әйбәт кебек, әмма тирә-юньдә кара йөрәкле кешеләр, аларның бәхетенә, эчкерсез мәхәббәтенә көнләшеп караучылар барлыгын да онытмаска кирәк. Китә гайбәт, имеш-мимешләр. Янәсе, Сафа Гәрәй хан да теге Җангалидән ерак китмәгән икән, шундый ук бер мәми авыз, хатыны сүзеннән чыкмый, ни кушса, шуны гына эшли торган ихтыярсыз ир. Имеш, дәүләт эшләрен дә ире исеменнән астыртын рәвештә хәйләкәр вә мәкерле Сөембикә үзе алып бара икән... Аллага шөкер, мондый гайбәтләргә каршы торырлык көч тә бар икән әле дөньяда. Мәхәббәт! Бер-береңә ихластан ышану. Төрле сынауларны уңышлы кичеп чыгарга ярдәм итә ул хисләр. Гомерләренең соңгы көннәренә кадәр Сафа Гәрәй белән Сөембикә мәхәббәтләренә тугрылыклы булып чыгалар, гайбәтләрдән өстен булып, бер-берсе белән аңлашып яшиләр.

Тик Казандагы хәлләр генә шәптән булмый. Кырымнан килгән түрәләрне үз янына туплаган Сафа Гәрәйнең эчке сәясәте күпләрдә ризасызлык уята. Казанлылар тагын бер хыянәткә баралар: 1545 елда Иван IV галиҗәнапларына мөрәҗәгатъ итеп, Кадыш һәм Чура бәкләр аннан һич кичекмәстән Казанга яу белән килүен үтенәләр.

Яу белән киләләр, әмма ул уңышлы булмый. Шулай да Казан морзалары ханга каршы корал күтәрәләр. 1546 елның гыйнварында Сафа Гәрәй – Кырымга, Сөембикә исә атасы янына, Нугай Урдасына качып китәргә мәҗбүр була.

Соңгы горурлык хисләрен һәм оятларын югалткан казанлылар, яңа хан сорап, Мәскәү патшасына тагын бер илчелек озаталар. Кемне куйсыннар инде урыслар? Килбәтсез Шаһгалине, әлбәттә. Шуны «җитәкләп», илчелек Казанга кайта. Җәй башында Шаһгалине тәхеткә утырталар.

Утырталар да бит, ә халык риза түгел. Беләләр ич аның кем икәнен – 1521 елда, үсмер чагында ук, хан булып алган иде ич. Абруе булмады. Хәзер дә шулай – берәүләр, икейөзлеләнеп, аның яклы булып кылана, икенчеләре яңа ханны бар дип тә белмиләр, аңа буйсынырга теләмиләр. Әлбәттә, мондый шартларда аңа ил башында озак утырырга туры килми. Өстәвенә Сафа Гәрәй дә тик ятмый. Башта ул Хаҗитархан ханына китә, аннан ярдәм булмагач, Сарайчыкка, Йосыф морза янына гозерләнеп килә.



Сөембикә, Үтәмеш, Сафа Гәрәй.
Рәссам *Канәфи Нәфыйков* картинасыннан репродукция

Йосыф морза тәвәккәл киявенә ярдәм кулы сузарга карар кыла.

Озак та үтми, Сафа Гәрәй яхшы гына коралланган нугай гаскәриләре белән Казанга кайта. Бернинди каршылыксыз кабул итәләр. Шулай итеп, Шаһгали бер-ике ай чамасы гына хан булып кала. Тәхеткә яңадан Сафа Гәрәй утыра. Боларны ишетеп, Иван IV аңа каршы сугыш игълан итә. Ләкин бу сугыш уңышсыз бетә.

Бер мәлгә Казан тынычланып калгандай була. Сарайчыктан Сөембикәне дә алып кайталар. Тормыш әкренләп үз рәтенә керә. Шатлык өстенә сөенеч дигәндәй, тиздән хан белән ханбикәнең көтеп алган уллары туа. Сабыйга Үтәмеш дип исем кушалар.

Шулай язгандыр инде – Казан тагын тузгытып ташланган кырмыска оясын хәтерләтә башлый. Гаеп, кем әйтмешли, атта да, тәртәдә дә була. Сафа Гәрәй, үзенең элекке сәясәтен дәвам итеп, җирле түрәләрне кыерсыта, иң мөһим дәүләт урыннарына Кырым кешеләрен билгели. Аңа каршы торучылар йә һәлак булалар, йә Мәскәүгә качып котылалар. Бу эштә, сизәсездер инде, Мәскәү хөкүмәте дә үз ролен оста уйный: ясалма каршылыклар тудырып, бердәмлеккә аяк чала, казанлылар арасында сугыш-талаш тудырып тора. Тегеләре исә, ханга ярдәм күрсәтер урынга, Мәскәү коткысына биреләләр. Ахыр чиктә Сафа Гәрәй Казан халкының теләктәшлеген югалта. Бигрәк тә Мәскәү яклы югары катлау кешеләре чаманы белмиләр, Сафа Гәрәйне чит итеп кенә калмыйлар, үзләренә дә һәлакәт киләсен аңламыйча, ханнан котылу юлын эзли башлыйлар. Ничек итеп дисезме? Мәскәү патшасы Иванны Казанга яу белән чакыралар. Яу оештырыла, әмма көтелгән нәтиҗәне бирми. Сафа Гәрәй казанлыларның мондый кыланышына аптырап кала. Ничек инде шулай? Ул, булган барлык мөмкинлеген, сәләтен эшкә җигеп, Казан иленең мөстәкыйльлеге өчен тырыша, урыс патшасына баш ияргә теләмичә, төрле ысуллар белән көрәшә. Мондагылар исә капма-каршы сәясәт алып баралар. Кырым белән Казан төркемнәре арасындагы хәлләр кискенләшә.

...1549 елның мартында Сафа Гәрәйне үтерәләр. Аңа әле кырык яшь тә тулмаган була. Ул Казан тәхетендә өч мәртәбә утырып (1524–1531, 1536, 1536–1549 еллар), җәмгысе 22 елга якын ханлык итә. Элеккеге һәм хәзерге тарихчы галимнәрнең бердәм бәяләмәсе шундый: Сафа Гәрәй Казан ханнарының иң бөекләреннән һәм куәтлеләреннән булып, ул хакимлек иткән еллар илнең төзек вә чәчәк аткан вакыты була.

## Фаҗигале елларда

Сөембикә һич көтмәгәндә ике яшьлек улы Үтәмеш Гәрәй белән тол кала. Сафа Гәрәйнең вакытсыз үлеме Казанның коточкыч фаҗига юлына басуын күрсәткән бер вакыйга булуын соңыннан гына аңларлар әле. Бу фаҗига, ни кызганыч, беренче нәүбәттә Сөембикә язмышында чагылачак.

Сөембикә үзен тиз кулга ала. Казан халкын билгесезлектә калдырырга ярамый – җебеп төшмәскә, тәвәккәлләргә, кыю адымнар ясарга кирәк! Мәрхүм иренең васыяте һәм ата-бабадан калган йола буенча хан тәхетенә сабые Үтәмеш Гәрәйне утырталар. Үсеп балигъ булганчы аның исеменнән Сөембикә үзе идарә итеп торачак. Тиз арада яңа хөкүмәт төзелә. Җитәкчесе итеп Сафа Гәрәй идарә иткәндә аның белән бергә Кырымнан килгән хан гвардиясе башлыгы, акыллы һәм батыр йөрәкле ир – Кошчак углан билгеләнә.

Ханбикәнең дәүләт хезмәтендәге тәүге адымнары түрәләр арасында бераз тынычлык урнаштырыр кебек була. Тик кая ул! Үтәмеш Гәрәйнең тәхеткә утыртылуыннан риза булмаган түрәләр хакимият өчен көрәшне туктатмыйлар. Сафа Гәрәйнең Кырымдагы өлкән улын, Булат Гәрәйне, хан итеп куярга өметләнеп, Бакчасарайга илчеләр җибәрәләр хәтта. Сәхиб Гәрәй хан, Сөембикә яклы булгандыр, күрәсең, ризалыгын бирми. Алай гына да түгел, Булат Гәрәйне, Казанга качып китмәсен дип, төрмәгә ябып куя (сүз уңаенда әйтеп үтик: Сәхиб Гәрәй шул үчле Булат кулыннан һәлак була).



Бу гына Сөембикәнең хәлен җиңеләйтми, әлбәттә. Өстәвенә Мәскәү патшасы да тынгы бирми. Сафа Гәрәй вафатыннан соң тәхеттә калган ике яшьлек сабый һәм аның анасы Сөембикә Явыз Иван тарафыннан берьюлы һәм мыскыллап, һәм шатланып каршы алына. Хатын-кыздан ни өмет итмәк кирәк, янәсе. «Казанны тулысынча буйсындырырга форсат килде», – дип уйлый ул. Һәм эшкә дә керешә. Ни гаҗәп, бу эшендә ул Сөембикәнең атасы Йосыф бәк ягыннан яклау таба. Йосыф бәк үзенең тол калган кызын Шаһгалигә бирергә уйлый дигән хәбәрләр ишетелә. Явыз Иванга язган хатында исә, Шаһгалигә Казанны алу өчен кирәк булган гаскәрне туплауда Мәскәүдәге татар түрәләре ярдәм итә алыр иде, дип киңәшләрен дә бирә. Моны ничек аңларга? Йосыф бәк шулай сөекле кызына каршы эш йөрткән микәнни? Кырым – ну-

Хан сараенда өйлә вакыты. Сөембикә улы Үтәмеш Гәрәй белән. Рәссам *Нияз Хаҗиәхмәтов* картинасыннан репродукция.



Шаһгали һәм Явыз Иван. Казан янында. Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция

гайларның күптәнге дошманы, берберсе белән гел сугышып, талашып торалар. Казан хакимиятендә кырымлылар өстенлек иткәч, Йосыф бәк үч йөзеннән шулай эшләгәндер, бәлки, дип уйларга да җирлек бар. Ахыр чиктә барыбер Сөембикәгә каршы юнәлдерелгән сәясәт булып чыга бит инде ул.

Кан дошманы Казанны ахыргача буйсындыру теләге белән янган Иван IV хәлиткеч сугышка әзерләнә. Нугай ханы фатихасын биреп торганда, нишләп сугышмаска ди. Дөрес, Казанны яулау җиңел булмаячак, ул – көчле ныгытылган кала. Халкы да мөстәкыйльлек өчен җанын фида кылачак. Димәк, бөтен көчне куеп, җентекләп әзерләнергә кирәк.

Сөембикә тарафыннан солых белән Мәскәүгә җибәрелгән илчелек уңышка ирешми. Киресенчә, Мәскәүдән сугыш белән киләләр. Гаскәр башында – Явыз Иван үзе. 1548–1549 елларның кышында, аннары 1550 елда Казанга ике зур һөҗүм ясала. Икесе дә җиңү китерми.

Соңгы сугыштан Мәскәүгә кайтып барышлый, Зөянең Иделгә коя торган култыгында, тау итәгендә Явыз Иван гаскәре белән ялга туктый. Аннары гаскәр башлыклары белән тау башына менә һәм бу урынның хәрби ныгытма – крепость кору өчен менә дигән җир икәнен күрә. Моннан Казанга һөҗүм итү бик уңай булачагын аңлый.

1551 елның 24 маенда Казан җиренең тау ягында, Зөя тамагында, урыс крепостена нигез салына. Бу эшләрдә бик актив рәвештә Шаһгали дә катнаша. Кала бер ай дигәндә төзелеп тә бетә, бөтен материалларны – крепость стеналарын, башня бураларын әзер килеш Угличтан су юлы белән ташыйлар. Иван патша тау ягын урыс җирләре дип игълан итә. Шул тирәдәге халыкны, татарын-чирмешен, патшага тугрылык сакларга ант иттерәләр. Казанлылар үзләренең борын төбендә яңа кала барлыкка килгәнен сизми дә калалар, чөнки шәһәргә илтүче юллар алдан ук киселгән, Казан үзе чолганышта калган була.

Әлбәттә, казанлыларга янаган куркыныч – Явыз Иванның тау ягы халкын буйсындыруы, күз



Сөембикә ханбикә хөкүмәт утырышында. Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция

ачып йомган арада диярлек Зөя (Свияжск) каласы торгызылуы – барысы да иртәме-соңмы Сөембикәгә барып җитә. Нишләргә? Ханбикә югалып калмый, Казан халкы белән киңәш тотып, саклану чараларына тотына. Шәһәр ныгытмалары яңартыла. Корал җитештерүче остаханәләрдә көне-төне эш кайный. Нугай, Хаҗитархан, Кырым ханнарына, гаскәр туплауда ярдәм сорап, чапкыннар җибәрелә. Тагын бер сорау борчый Сөембикәне – әтисе ярдәмгә килерме? Сөекле кызын һич ташламас, илгә янаган афәт алдында берүзен ялгыз калдырмас кебек.

Әйе, Йосыф бәк кызын ялгыз калдырмаска дигән карарга килә. Тик менә бертуган энесе Исмәгыйль морза гына киреләнә. «Мин гомер буе Мәскәү белән дус яшәдем, аңа каршы сугышсам, сәүдә эшләрем таркалачак», – ди ул. Йосыф бәк белән Исмәгыйль морза арасындагы дошманлыкны, аларның үзара гел тарткалашып торуын урыслар да яхшы белә. Шунлыктан, күрәсең, Исмәгыйль янына Иван патшадан илче дә килеп җитә. Кыскасы, Исмәгыйль морза Мәскәүгә яу белән чыкмый, Казанга ярдәм кулы сузмый.

Сөембикәнең хәле һаман катлаулана бара. Гаскәр әле сугышка әзер түгел. Мари-чуаш ягы, Мәскәүдән котылыр әмәл булмас инде дип, Иван патшага буйсынырга карар кыла. Казан халкының да бер өлеше Мәскәү яклы. Түрәләрен әйтәсе дә юк инде. Җитмәсә, бердәнбер таянычы-киңәшчесе Кошчак углан белән кыен, әйтергә кирәк, фаҗигале хәл килеп чыга. Халык арасында, Кошчак

углан белән Сөембикә, Үтәмеш сабыйны юк итеп, тәхетне үз кулларына төшермәкчеләр икән дигән коточкыч хәбәр тараталар. Нахаксыз гаепләүләргә түзеп тора алмыйча, Кошчак углан хатынын, ике баласын һәм энесен ияртеп, өч йөзләп сугышчысы белән төнлә Казаннан чыгып качарга мәҗбүр була. Ул: «Кырымнан урыс илбасарларына каршы тора алырлык гаскәр алып киләчәкмен», – дип морзаларга үз ниятен аңлата. Тегеләр бу хәбәрне шундук Шаһгалигә җиткерәләр. Кошчак углан артыннан урыслар гаскәр җибәрә. Камага җитәрәк качакларны куып тоталар. Күбесе канлы бәрелеш вакытында һәлак була, исән калганнарын – барлыгы 46 кешене, шул исәптән Кошчакны һәм аның гаиләсен дә – әсирлеккә алып, Мәскәүгә озаталар. Барысын да җәзалап үтерәләр.

Сөембикә өчен бу әйтеп бетергесез олы югалту була. Ул ялгызы кала.

Казанда яңа хөкүмәт сайлана. Аның башында Сөембикәнең дошманнары, Мәскәү яклы кешеләр – Ходайкол углан белән Нурали Ширин морза (Булат Ширинның улы) тора. Иң башта алар Зөя каласына Кол Шәриф җитәкчелегендә илчелек җибәрәләр. Максатлары Казанны урыс баскыннарыннан саклап калу була. Ике арада солых төзелә. Анда мондый шартлар куела:

– шәһәрдә булган барлык урыс әсирләрен һич кичекмәстән азат итәргә, кырымлыларны исә Мәскәү патшасына тапшырырга;
– казанлылар, Үтәмеш Гәрәй ханны һәм аның әнисе Сөембикәне кулга алып, Мәскәүгә, «шөһрәтле тоткынлыкка» озатырга тиешләр;
– Казан ханы итеп тәхеткә Шаһгалине утыртырга.

Яңа хөкүмәт солых килешүендә күрсәтелгән шартларны үтәргә керешә.

Башта тоткыннарны иреккә чыгаралар. Имештер, «еллар буе коточкыч газаплар күреп яткан» урыс тоткыннарның саны 100 меңгә җиткән – менә нинди кансыз алар, казанлылар! 1564–1565 елларда билгесез бер урыс кешесе язган «Казан тарихы»нда шулай диелгән. Әлеге санга игътибар ит, укучым. Рәсәй мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында укытыла торган бөтен дәреслекләргә кертелгән ул. Галимнәрнең әйтүе буенча, Казанда ул вакытларда халык саны 8–10 мең кешедән артмаган. Шуларның яртысы эшкә яраклы булгандыр инде. Һәм шул халык 100 мең әсирне асрап ятсын, имеш. Кеше ышанмастай хәл бу! Димәк, бу уйдырма казанлыларның баскын халык икәнлекләрен күпертеп күрсәтү өчен махсус уйлап чыгарылган.

Солыхның икенче шарты да җентекләп үтәлә. Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәйне тоткынлыкка алып китү өчен 4 мең кешелек (!) гаскәре белән Мәскәүдән Петр Серебряный исемле кенәз килә.

Юлга әзерләнү өчен Сөембикәгә ун көн вакыт бирәләр. Ун көн буе ул каты сак астында ята. Шул арада казнадагы хәзинәләрне барлап, елга буендагы көймәләргә төяп куялар. Алтын-көмеш савыт-саба, бизәнү әйберләре, энҗе-мәрҗән, асылташлар, кыйммәтле мехлар, затлы кием-салым, яхшы корал белән унике зур көймә тула.

Ун көн узып та китә. Казан белән мәңгегә хушлашыр алдыннан кенәз Серебряный Сөембикәгә ире Сафа Гәрәй кабере белән хушлашырга рөхсәт итә.



Сөембикә Сафа Гәрәй хан кабере янында.
Рәссам *Нияз Хаҗиәхмәтов* картинасыннан репродукция

Менә ул Сафа Гәрәй кабере янында. Күз яшьләрен тыя алмыйча, сулкылдап елый, иренә йөрәк түреннән чыккан хушлашу сүзләрен ирештерә.

...Һуштан язып егылган ханбикәне күтәреп алып китәләр. Юлның ике ягына тезелгән халык аны күз яшьләре белән озатып кала.

Елга буена килеп җитәләр. Кайгы-хәсрәт баскан, аягында көчкә басып торган Сөембикәне, ике кулыннан тотып, арбадан төшерәләр. Ханбикә елга буена җыелган халык белән хушлаша. Аны зур көймәгә кертеп утырталар.

Махсус әзерләнгән урында бераз хәл җыеп алгач, авыр, әмма хак сүзләрен әйтеп калу өчен, Сөембикә яңадан яр буена, халык алдына чыга:

– Бәхетсезлек һәм фаҗига кунды синең өскә, сөекле калам. Кайда югалттың син башыңдагы кыйммәтле, кодрәтле, азатлык нуры белән бизәлгән таҗыңны? Кем тартып алды аны синнән? Кем хәзер синең ирегеңне вә азатлыгыңны саклап кала алыр? Синең гайрәтле һәм дә акыллы ханың бу фани дөньядан күптән инде мәңгелек йортына күчте. Көчле-куәтле гаскәр башлыклары – морза-угланнар хәлсезлән-



Сөембикәнең хушлашуы.
Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция

гәннәр. Байтагы дошманнарга сатылган. Халкың да туктаусыз дәвам иткән ызгыш-талашлардан интегеп беткән. Заманында зур булышлык вәгъдә иткән тугандаш халыклар да сиңа ярдәмгә килә алмады. Әнә шуңа күрә син җиңелдең.

Үземнең вә илемнең бәхетсезлеге турында кадерле ата-анама ничек кенә хәбәр итим икән? Әллә кайгы-хәсрәтемне кош каурыена язып юллыйммы? Бу канлы көннәрдә син минем берләнбер ярдәмчем булып каласың, Аллаһы Тәгаләм! Үзең тарт инде кирәк тапкан җәзаңа минем кан дошманым – үз халкын вә илен саткан бәндәне – Шаһгалине, Казан вә казанлыларны саткан түрә-морзаларны! Барлык мөселман халыкларының мәңгелек дошманы булган Мәскәү патшасына да ләгънәт төшсен! Ни хакы бар аның безне туган илебездән куып чыгарырга? Нигә ул безне тоткын итә? Миңа бит аңардан берни кирәкми. Мин бит аңардан берни сорамадым, таләп итмәдем, берни үтенмәдем. Бирсен иде ул миңа үз җиремдә бәләкәй генә олыс* кисәге. Һичьюгы, җибәрсен иде үземнең туган җиремә – Җаек якларында, киң далаларда урнашкан Нугай иленә, сөекле әтием Йосыф бәк янына. Мондый хурлыкка калганчы, шушы җирдә, Казан илендә вакытында җан биргән булсамчы! Нишләп соң мин шул урыс илендә иң бәхетсез бәндәләрнең берсе булып калырга тиешмен? Йа Хода!..

Бу вакыйга 1551 елның 11 августында була. Бу көнне Казан халкы озак онытмаячак әле.

5 сентябрьдә Сөембикә белән дүрт яшьлек Үтәмеш Гәрәй угылны Мәскәүгә китереп җиткерәләр. Ханбикәбез тормышында аны ахыр чиктә олы фаҗигагә китергән кара көннәр башлана.

## Сөембикә һәм Шаһгали

1552 елның 2 (12) октябрендә Явыз Иван гаскәрләре Казанны штурм белән алалар. Патша исән калган ирләрне үтереп бетерергә, хатын-кызларны һәм балаларны әсирлеккә алырга әмер бирә. Шәһәрне таларга рөхсәт ителә. Казан ханлыгы яшәүдән туктый, аның җирләре Урыс дәүләтенә кушыла.

Шаһгали тиздән сугышчылары белән Мәскәүгә кайтып китә. Явыз Иван Сөембикәне Шаһгалигә көчләп кияүгә бирә.

Йосыф морза ни карый? Ул үзенчә тырыша, тик яткан дип һич тә әйтеп булмый. Әле Сөембикәне Мәскәүгә алып киткәнче үк, аңа ярдәм кулы сузарга омтыла, әсирлектән коткарып калу максаты белән ике тапкыр үзенең гаскәрен Казанга җибәрә. Әмма ике тапкырында да уңышсызлыкка очрый: нугай сугышчыларын ханлык чигенә җитәрәк урыс яугирләре каршы ала. Очрашу канлы фаҗига белән тәмамлана.

Йосыф бәк белән Явыз Иван арасында хат алышу башлана. Мәскәү патшасыннан Йосыф бәк бары тик бер нәрсәне гозерләнеп сорый: азат итсен ул Сөембикә белән Үтәмеш сабыйны тоткынлыктан,

---

* Олыс – мөстәкыйль биләмә.



Касыйм шәһәре күренеше. Рәссам *Фиринат Халиков* картинасыннан репродукция

кайтарып җибәрсен икесен дә атасы янына, Нугай далаларына. Хатлары катгый һәм ачулы була. Бик тә гадел һәм үтәү өчен җиңел таләпләр югыйсә. Иван җавапсыз калмый, Йосыф картка матур-матур хатлар җибәрә тора. Берсендә ул, мәсәлән, болай яза: «Мөхтәрәм Йосыф бәк! Без сиңа махсус илчелек тә җибәргән идек. Сөендек Тулусыпов, кызың турында әйбәт хәбәр әйтсен, кызыңның нинди яхшы шартларда яшәве турында сөйләсен дип. Ул илче сиңа барып җиткәндер вә сиңа Сөембикәнең шатлыклы хәбәрләрен әйткәндер инде».

Иван патша Шаһгалигә дә хат юллый: «Нугай далаларында Сөембикә турында ниндидер бик ямьсез хәбәрләр таралган икән. Кемдер Йосыф бәккә тузга язмаган хәбәрләр сөйләп бетергән. Имеш тә, Сөембикәне без җәзага тартканбыз, аның борынын кистергәнбез, имгәтеп бетергәнбез. Йосыф бәк кешеләре Җангали белән Бәхеткилде сиңа килгәндә, син өеңдә бул, күрсәт син аларга Сөембикәне. Әгәр теләге булса, Сөембикә үзенең исәнлеге, аңа берни дә булмавы турында ата-анасына хат язсын. Сөембикә хатларының күчермәсен безгә дә җибәрерсең».

Шаһгалигә Иван патша тагын бер хат җибәрә. «Син үзең дә Йосыф бәккә хат яз», – ди ул әлеге хатында. – «Безнең аны ничек яратканны бәйнә-бәйнә сөйлә. Нинди зур хөрмәт-тантана белән безнең Сөембикәне сиңа кияүгә биргәнне хәбәр ит. Аның нинди яхшы шартларда, нәкъ менә хан кызыдай яшәвен сөйлә. Ханбикә малаен үзебезнең баланы караган кебек карыйбыз, дип әйт. Мин әйткәннәрнең барысын да эшләгәч, соңыннан миңа да хат язарсың...»

Менә шулай. Беренче карашка барысы да әйбәт бара кебек. Тик әлеге хатларда Иван патшаның икейөзлеләнүен, алдап-йолдап булса да, Сөембикәнең хәлен әйбәт дип күрсәтергә омтылуын, боларның барысы да чеп-чи ялган икәнен күпләр, шул исәптән Йосыф бәк үзе дә аңлый. Чынлыкта, авыр иде, бик тә авыр иде Сөембикәнең хәлләре.

Сөембикәне Шаһгалигә көчләп кияүгә бирәләр, дидек. «Беркайчан да бу адәм актыгының хатыны булмаячакмын!» – дип ачыктан-ачык йөрде ич ул. Әмма менә ничек килеп чыкты. Шаһгалинең тышкы кыяфәте үк гайрәтеңне чигерерлек: каратут йөзле, салынкы озын колаклы, кыска аяклы, зур корсаклы, табак битле сөйкемсез бер зат. Болары бер нәрсә, өстәвенә, сатлыкҗан, мал һәм тамак хакына иленә, халкына хыянәт иткән кабахәт җан. Тарихта аның исемен кара хәрефләр белән язып куячаклар әле.

...Мәскәүдә никах туйларын уздырып, Сөембикәне, сөекле углы, газизе Үтәмеш Гәрәйдән аерып, Касыйм шәһәренә – Шаһгалинең туган ягына алып кайтып китәләр. Нишләргә? Ничекләр яшәргә? Ире белән алыш-биреше, эч серләрен бушатырлык ахирәте юк. Көннәр, атналар буе берни дәшми яшәвен белә Сөембикә. Әгәр дә моны яшәү дип әйтергә яраса. Нугай якларыннан да шомлы хәбәрләр генә килеп тора. Әнә Мәскәүдән тагын бер коточкыч хәбәр алды: сабыен чукындырганнар, Александр дип исем кушканнар. Киләчәккә соңгы өмет тә сүнде, янып-көеп яшәүнең мәгънәсе калмады дип уйлый Сөембикә.

Соң чиккә җиткереп мәсхәрәләнгән Сөембикәбез күзгә күренеп сула, саргая, ашаудан кала һәм, яшәү газабын кичерә алмыйча, 1557 елда дөньядан китә. Бу вакытта аңа нибары 38 яшьләр чамасы була.

## Сөембикәне сагыну

Гаҗәп хәл, халык бүген дә, вафатыннан дүрт йөз илле елдан артык вакыт үтсә дә, Сөембикәсен сагына. Газиз кызының аяныч язмышы турында риваятьләрдә, бәетләрдә сөйли, аңа багышлап җырлар, шигырьләр иҗат итә. Һәм боларны түкмичәчми буыннан буынга тапшыра килә. Ни өчен? Чөнки Сөембикә фаҗигасе – безнең фаҗига ул. Бөтен татар халкының фаҗигасе.

Сөембикәнең үлем хәбәрен ишетү халыкны тетрәтә һәм ул «Сөембикә бәете»н чыгара.

Шул заманнардан бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән халык иҗаты әсәрләре бихисап. Ул әсәрләрдә Сөембикә тормышыннан алынган кызыклы мәгълүматлар китерелә, нигезендә чынбарлык яткан вакыйгалар тасвирлана. Алар тарих фәненең үсешенә дә этәргеч бирәләр. Сөембикә фаҗигасендә Казан ханлыгының тарихи фаҗигасе көзгедәге кебек ачык чагыла.



Сөембикә. *Бакый Урманче* скульптурасы



Казан Кремлендә Сөембикә манарасы

...Казан Кремле уртасында башына ярым ай куелган Сөембикә манарасы балкып тора. Ул шәһәребезнең борынгы архитектура символы. Бу манара хакында халыкта бик күп риваятьләр йөри. Менә аларның берсе. Имештер, Явыз Иван, Казанны басып алырга килгәч, Сөембикә ханбикәнең гүзәллеге, чибәрлеге турында ишетеп, аны хатынлыкка алмакчы була һәм яучылар җибәрә. Горур һәм акыллы ханбикәбез әлеге тәкъдимнән баш тарта. Ачуы чыккан урыс патшасы сугышчылары белән Казанны камап ала. Сөембикә хәйлә кора: әгәр дә җиде тәүлек эчендә Иван патша җиде катлы манара төзеп куйса, кияүгә чыгармын, ди. Иван риза була һәм төзелеш эшләре башланып китә. Җиде тәүлек дигәндә манара әзер дә була. Шул вакыт Сөембикә манарага күтәрелә һәм, урыс патшасына бирелергә теләмичә, җиргә ташлана. Шушы вакыйганы мәңгеләштереп, манараны Сөембикә исеме белән атый башлаганнар, имеш.

Икенче риваять буенча, Сөембикә манарасы – ханбикәнең дошманнар тарафыннан үтерелгән ире Сафа Гәрәйгә багышлап махсус салдырткан истәлек корылмасы. Сафа Гәрәй кабере өстенә куелган, имеш.

Ниһаять, дөреслеккә бик тә якын торган һәм халык арасында киң таралган тагын бер риваять. Бусы да борынгыдан килә. Сөембикә манарасы – Хан мәчетенең манарасы, диләр бирегә гыйбадәт кылу өчен килгән әби-бабайлар...

Чыннан да, серле булып чыкты ул Сөембикә манарасы. Галимнәргә күптәннән инде тынгылык бирми. Төп сорау – кайсы чорда төзелгән? – әллә никадәр фаразлар туура сәбәпче булды. Фәнни әдәбиятта шундый бер кызыклы хәл күзәтелә: урысларның дин әһелләре генә түгел, дәрәҗәле тарихчылары да, Сөембикә манарасы ул безнеке түгел, аны, һичшиксез, әле ханлык чорында ук татарлар салганнар, әйдәгез, бу хакта бәхәсләшеп тә тормыйк, дип әйтәләр. Кайбер галимнәребез исә, фәнни дәлилләр табып, манараны һаман яшәртмәкче, урыс халкыныкы итмәкче булалар.

Кайсы фараз дөреслеккә туры килә?

2001 елда без Сөембикә манарасына якын гына җирдә, аның төньяк һәм төньяк-көнчыгыш ягында, казу эшләре алып бардык. Биредә ханлык чорында таштан салынган зур гына бина калдыклары ачылды. Аның озынлыгы 30, киңлеге 16 метрга җитә иде. Ул нәкъ Мәккәгә, кыйблага каратып салын-

ган. Бу урында хан мәчете булганмы? Шулай кебек, әлегә бу бары тик фаразлау гына. Җир астыннан казып чыгарылган әлеге бина Сөембикәне хәтерли кебек.

Безне менә нәрсә гаҗәпләндерде: Сөембикә манарасының төньяк-көнчыгыш нигезе нәкъ менә шушы ханнар чорында салынган бина өстендә «утыра». Димәк, ул, әлеге мәчет, Сөембикә манарасын төзегәндә җимертелгән була инде. Шулай микән? «Сөембикә» урыс чорына караган архитектура истәлеге дип ялгышмыйбыз микән? Миңа калса, юк, ялгышмыйбыз. Сөембикә заманында, Сафа Гәрәй вафатыннан соңгы гаугалы ике ел эчендә әле бүген дә зурлыгы-биеклеге белән шаккатырырлык мондый корылманы төзү һич мөмкин булмаган. Хәзерге заман мәчет манаралары да күпкә кечерәк. Шуны да онытмыйк: Казан ханлыгы – Урта гасыр төрки-татар цивилизациясенең әкренләп сүнеп бару чоры. Ул чакта Болгар илендәге кебек мәшһүр калаларның эзе дә булмаган. Хәтта Казанны да зурлыгы-байлыгы ягыннан Болгар, Биләр, Суар белән чагыштырып булмый. Ыгы-зыгыдан башлары чыкмаган ханнар акча сугу эшен дә оештырып җибәрә алмаганнар ич. Бүгенгә кадәр фәндә бер генә Казан ханының да акчасы (тәңкәсе) мәгълүм түгел. Зәгыйфьләнгән ил башлыгы, шундый авыр, каршылыклы шартларда көч-хәл белән тырышып-тырмашып идарә кылучы Сөембикә, сөекле иременең истәлеген мәңгеләштерәм дип, кулыннан килмәслек эшкә тотынмас та иде. Шуңа күрә манараның ханлык таркалганнан соңгы елларда салынган булуы белән килешергә кирәктер, минемчә.

Ни генә булмасын, халкыбыз хәтеренә Сөембикә манарасы Хан мәчете урыны буларак кереп калган. Әле бүген дә өлкән яшьтәгеләр бирегә килеп дога кылалар, яуларда шәһит булганнарны искә төшерәләр, илгә иминлек телиләр.



*Рада Нигъмәтуллинаның* Сөембикә ханбикәгә багышланган һәйкәл проекты автор үзе күрергә теләгән урында

*Хөрмәтле укучылар, Сөембикәнең фаҗигале язмышы язучыларны, шагыйрьләрне, тарихчы галимнәрне беркайчан да битараф калдырмаган. Аның турында бай әдәбият бар. Шуларның иң кызыклыларын сезгә дә укырга тәкъдим итәбез. Менә алар:*

*Атласи Һади*. Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

*Батулла Рабит*. Сөембикә: кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

*Нәүрүзхан Илгиз Ваһап*. Сөембикә: тарихи роман / төрекчәдән Р.Сабиров тәрҗемәсе. – Чаллы: КамАЗ, 1992.

Сөембикә ханбикә: җыентык: тарихи, фәнни хезмәтләр, бәяннар, әдәби әсәрләр, әсәрләрдән өзекләр / төзүчесе С.И.Ибраһимова. – Казан: Идел-Пресс, 2001.

*Урманче Фатих*. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

*Фәхретдин Ризаэтдин*. Казан ханнары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Хәбибуллин Мөсәгыйт*. Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный: тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.

# ЭЧТӘЛЕК

## Кол Гали

Кол Гали — болгар шагыйре ........................................... 4
«Кыйссаи Йосыф» поэмасы ............................................ 9
Тагын бераз Кол Гали турында ..................................... 18

## Кол Шәриф

Кол Шәрифнең тормыш юлы ........................................ 20
Кол Шәриф иҗаты ........................................................ 24

## Сөембикә

Нугайлар ...................................................................... 26
Сөембикәнең яшьлеге .................................................... 28
Сөембикә һәм Җангали ................................................. 30
Сөембикә һәм Сафа Гәрәй ............................................. 32
Фаҗигале елларда ........................................................ 36
Сөембикә һәм Шаһгали ................................................. 41
Сөембикәне сагыну ....................................................... 43

Научно-популярное издание

***Хузин** Фаяз Шарипович*

Серия «Личности»

КУЛ ГАЛИ. КУЛ ШАРИФ. СЮЮМБИКЕ

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Фәнни-популяр басма

***Хуҗин** Фаяз Шәрип улы*

«Шәхесләр» сериясе

КОЛ ГАЛИ. КОЛ ШӘРИФ. СӨЕМБИКӘ

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2009. Форматы 84´90$^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 4,20. Тиражы 2000 д. Заказ Т-1669.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.